СИШӘМБЕ
31
ДЕКАБРЬ
1940 ел.
№ 304 (6104)
Аерым номеры 10 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ, ШӘҺӘР КОМИТЕТЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Укытучыларны марксизм-ленинизм теориясе белән коралландыруга игтибарны көчәйтик

Совет интеллигенциясе үзенең социаль чыгышы ягыннан да, шулай ук көндәлек эше ягыннан да эшчеләр сыйнфы һәм крестьяннар белән турыдан-туры бәйләнгән. Безнең интеллигенциябезнең гаять зур күпчелеге дәүләт эше өчен, социалистик Ватан эше өчен үзенең бөтен көчен һәм барлык энергиясен биреп, чын күңелдән эшли. Социалистик интеллигенция—ул бөтенләй яңа тип интеллигенция, аның кебек интеллигенциянең дөньяда бер генә илдә дә булганы юк.

Партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан халык укытучысына яшь буынны коммунизм рухында тәрбияләү, аның дөньяга карашын формалаштыру, аны тирән белемле, югары культуралы кеше итеп, коммунизм җәмгыятенең аңлы һәм актив көрәшчесе итеп тәрбияләү кебек гаять мактаулы һәм җаваплы бурыч йөкләнгән. Бу мактаулы һәм җаваплы бурычны уңышлы рәвештә тормышка ашыру өчен безнең укытучыларыбыз үзләре дә тирән белемле, югары культуралы һәм, барыннан да элек, деньяда иң революцион теория белән, марксизм-ленинизм теориясе белән коралланган булырга тиешләр. Җәмгыятнең үсеш законнарын, пролетариат революциясенең, социалистик төзелешнең үсеш законнарын, коммунизмның җиңүе турындагы законнарны белми торып, данлыклы большевиклар партиясенең героик тарихын үзләштерми торып чын магнәсе белән тәрбияче булырга мөмкин түгел.

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ басылып чыгу һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының пропаганда турындагы карары интеллигенцияне, шул исәптән укытучыларны, революцион теория белән коралландыруда гаять зур чараларның берсе булдылар. Хәзер инде укытучылардан бик күп иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүне тәмам итеп, Маркс, Энгельс, Ленин, Сталинның аерым әсәрләрен өйрәнү өстендә, философия, политэкономия, тарих фәннәрен үзләштерү өстендә җитди эш алып баралар.

Норлат урта мәктәбе директоры иптәш Әмирханов үзенең теоретик белемен күтәрү өстендә тырышып эшли. Энгельснең „Табигат диалектикасы“, „Анти Дюринг“, „Людвиг Фейербах“ дигән әсәрләрен, Маркснын „Политэкономиягә тәнкыйть“ дигән әсәрен, Ленинның „Материализм һәм эмпириокритицизм“, „Империализм—капитализмның иң югары стадиясе“ һәм башка күп кенә әсәрләрен өйрәнгән. Үзлегеннән немец теле өйрәнә. Матур әдәбиятны системалы рәвештә укып бара. Дингә каршы лекцияләр укый. Ворошилов районы, Сәмәкәй авылы укытучысы иптәш Исламов та марксизм-ленинизм теориясен үзләштерү буенча системалы эш алып бара. Марксизм-ленинизм классикларының күп кенә әсәрләрен өйрәнгән. Хәзер Лениннең „Материализм һәм эмпириокритицизм“ дигән әсәрен өйрәнә. Ул үзе белән бергә эшләүче иптәшләренә һәр вакыт ярдәм итә. Алар белән консультация һәм беседалар үткәрә. Тәкәнеш урта мәктәбе укытучысы иптәш Шакиров Маркс, Энгельс, Ленин, Сталинның күп кенә әсәрләрен өйрәнгән. Ул матур әдәбияттан да бик күп китаплар укыган.

Мондый иптәшләрне һәрбер районда очратырга була. Мәсәлән, Әлмәт районында „Кыскача курс“ны өйрәнүне 55 кеше тәмам иткән, шулардан 45 кеше укытучылар. Баулы районында „Кыскача курс“ны өйрәнүне тәмам итүчеләр 70 кеше исәпләнә. Шулардан 50 кеше укытучылар.

Ләкин бу әле безнең барлык укытучыларыбыз да үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү өстендә җитәрлек эшлиләр дигән сүз түгел. „Кыскача курс“ның чыгуына ике елдан артык вакыт үтүгә карамастан, I—IV нче бүлекләрне өйрәнүдән ерак китә алмаучы укытучылар да бар әле. Мәсәлән, Кузнечиха районы Чув. Бурнаево авылы укытучыларыннан Кондратьев, Николаева иптәшләр партия тарихын бик акрын өйрәнәләр. Шулай ук, Теләче районы укытучыларыннан күп кенә иптәшләр төрле курсларда укыган вакытта партия тарихын өйрәнгән булсалар да,—хәзер алар шуның белән генә чикләнеп калганнар. Мондыйлар рәтенә Тунгускова, Камалов, Климентьев, Моратов, Иванов иптәшләрне кертергә була. ВКП(б) ның Теләче райкомы „Кыскача курс“ны өйрәнүне тәмам иткән укытучылар белән бер төрле дә эш алып бармый. Парткабинет кичке сәгать 8 гә кадәр генә ачык була, ял көннәрендә бөтенләй эшләми. Укытучылар белән консультация һәм беседалар бөтенләй диярлек үткәрелми.

ВКП(б) ның Красный Бор райкомы укытучыларның партия тарихын өйрәнү эшләре белән җитәрлек кызыксынмый. Ә ВКП(б) ның Беренче Май райкомында, хәтта, укытучылардан партия тарихын үзлегеннән районда күпме кеше өйрәнгәнен дә белмиләр. Шунлыктан, Беренче Май районында марксизм-ленинизм теориясен үзлегеннән өйрәнүче укытучыларга булган ярдәмнең торышы бик йомшак.

Кайбер урыннарда „укытучыларга партия тарихын өйрәнүдә ярдәм итмәгәндә дә була, алар теорияне үзлекләреннән дә өйрәнә алалар“ дип карыйлар. Дөрес, укытучылар, һичшиксез, белемле, культуралы кешеләр, аларның күбесенең китап белән эшләүдә бай тәҗрибәләре һәм күнекмәләре бар, бу исә аларга революцион теорияне өйрәнүдә беркадәр җиңеллек бирә. Ләкин, бу әле укытучылар бернинди дә ярдәмгә мохтаҗ түгелләр дигән сүз түгел.

Югары сыйфатлы лекцияләр, консультацияләр, тәҗрибә уртаклашу киңәшмәләре һәм индивидуаль беседалар марксизм теориясен үзлекләреннән өйрәнүчеләргә, шул исәптән укытучыларга да гаять зур ярдәм итәләр. Большевиклар партиясе тарихын өйрәнүче һәрбер иптәшкә индивидуаль якын килергә, җитди ярдәм күрсәтүгә игтибар бирергә кирәк.

Безнең шартларда укытучыларның төрле яклап тирән белемле, югары культуралы булу, җәмгыятнең үсеш законнарын тирән белү белән коралланулары өчен бөтен мөмкинлекләре бар. Партиябез, хөкүмәтебез һәм бөек Сталин укытучылар турында бер туктаусыз кайгыртучанлык күрсәтәләр. Укытучы—бөтен халык тарафыннан иттибар һәм зур авторитет белән файдалана. Безнең җәмгыятебездә укытучыларның тоткан урны чиксез зур. Шуның өчен дә, укытучыларны идея политик яктан тәрбияләү мәсьәләсе партия оешмаларының иң зур бурычларыннан берсе булып тора.

„Безнең җәмгыятнең тагын да күтәрелүе һәм тулысынча чәчәк атуы өчен шул кадәр шартлар, шул кадәр мөмкинлекләр тудырылган ки, хәзер инде бездә иң әһәмиятле нәрсә—үзеңнең хезмәтеңә коммунистик аңлы караштан һәм, бигрәк тә, җәелеп үскән совет интеллигенциясе кадрларын идея ягыннан тәрбияләү буенча безнең большевистик эшебезне уңышлы алып барудан гыйбарәт“. (Молотов).

БЕР СМЕНАГА 319 СУМ ХЕЗМӘТ ХАКЫ

Серго Орджоникидзе исемендәге завод стахановчылары ВКП(б) ның XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе исемендәге социалистик ярышта әледән-әле яңа уңышлар яулап алалар.

Мәсәлән, заводның мактаулы стахановчысы, ВКП(б) кандидаты иптәш Смирнов 30 нчы декабрьдә конференция исемендәге вахтага басып, сменалык нормасын 2.016 процентка үтәде һәм бу сменада ул 319 сум хезмәт хакы эшләде.

Казан шәһәре советы депутаты, стахановчы слесарь Солтан иптәш Әхмәтгәрәев үзенең ярдәмчесе иптәш Королев белән 30 нчы декабрьдә 5 сәгат 40 минут эчендә норманы 1.211 процент итеп үтәде. Шушы вакыт эчендә ул 113 сум 55 тиен, аның ярдәмчесе иптәш Королев 64 сум 89 тиен хезмәт хакы эшләделәр.

Бари Корбанов.

Язу машиналары заводының инструменталь цех стахановчылары ВКП(б) ның XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе хөрмәтенә производство планын 200 процентка үтәргә сүз бирәләр. Сулдан уңга: инструменталь цех стахановчыларыннан Н. Казачкин, Ф. Мәрдәнов, И. Ипатов һәм П. Неделько иптәшләр.

И. Галиев фотосы.

Яңа Чишмә һәм Минзәлә сайлау округларында сайлау кампаниясе

„ҮСӘР“ КОЛХОЗЫНДА ҖЫЕЛЫШ

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ СОЮЗ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛЫГЫНА ЯҢА ЧИШМӘ САЙЛАУ ОКРУГЫННАН КАНДИДАТ ИТЕП ТАТАРСТАН АССР СОВНАРКОМЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ СӨЛӘЙМАН ХӘЛИЛ УЛЫ ГАФИЯТУЛЛИННЫ КҮРСӘТӘЛӘР

АКСУБАЙ, 30 декабрь. (ТатТАСС). 29 нчы декабрьдә „Үсәр“ колхозында иртәдән үк зур җанлылык башланды. Бу көнне СССР Верховный Советы депутатлыгына кандидат күрсәтү буенча гомуми җыелыш үткәрелә. Иртәнге 11 сәгаттә колхоз клубы сайлаучылар белән тулды.

СССР Верховный Советы депутатлыгына кандидат күрсәтүгә багышланган җыелышны Яңа Ибрай авыл советы башкарма комитеты председателе иптәш Габдулла Вәлиуллин ача.

Президиум сайланганнан соң сүз колхоз агротехнигы, иптәш Сабир Әбраровка бирелә.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенең Баш Комитеты тарафыннан Кече көмеш медаль белән бүләкләнгән иптәш Әбраров СССР Верховный Советы депутатлыгына Яңа Чишмә сайлау округыннан кандидат итеп большевиклар партиясенең турылыклы улы, Татарстан АССР Совнаркомы председателе иптәш Сөләйман Хәлил улы Гафиятуллинны күрсәтү турында такдим кертә. Җыелышта катнашучылар Әбраровның бу сүзләрен көчле алкышлар белән каршы алалар. Аннан соң чыгыш ясап, колхоз председателе иптәш Гыйниятуллин иптәш Гафиятуллин кандидатурасын яклап сөйли.

Колхоз янындагы башлангыч партоешма секретаре иптәш Шәйхеттинов болай ди:

— „Мин иптәш Гафиятуллин кандидатурасын кайнар рәвештә котлыйм һәм аны яклыйм“. Колхозчылардан Маслахов, Хөснетинов һәм башка иптәшләр дә шул ук турыда сөйләделәр.

Аннары җыелыш бердәм рәвештә түбәндәге резолюцияне кабул итте:

„Союз Советына Яңа Чишмә сайлау округыннан депутатлыкка кандидат күрсәтү турында Сабир иптәш Әбраров тарафыннан ясалган белдерүне тыңлап, „Үсәр“ колхозы членнарының гомуми җыелышы карар бирә: Союз Советына Яңа Чишмә сайлау округыннан депутатлыкка кандидат итеп, Ленин—Сталин партиясенең турылыклы улы, Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы председателе, орденлы иптәш Сөләйман Хәлил улы Гафиятуллинны күрсәтергә. Гомуми җыелыш Яңа Чишмә сайлау округыннан Союз Советы депутатлыгына тавышка куелуга иптәш Гафиятуллинның ризалык бирүен сорый“.

Аннары җыелыш иптәш Гафиятуллин кандидатурасын якларга һәм сайлаулар көнендә, 19 нчы январьда, үзләренең тавышларын коммунистларның һәм партиясезләрнең җиңелмәслек блогы кандидаты иптәш Гафиятуллинга бирергә чакырып, Яңа Чишмә сайлау округындагы барлык сайлаучыларга мөраҗәгать кабул итте.

ТИМЕР ЮЛЧЫЛАР КАНДИДАТЫ

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ МИЛЛӘТЛӘР СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛЫГЫНА МИНЗӘЛӘ САЙЛАУ ОКРУГЫННАН КАНДИДАТ ИТЕП ТАТАРСТАН АССР НЫҢ ЭЧКЕ ЭШЛӘР ХАЛЫК КОМИССАРЫ ИПТӘШ ЕФРЕМ МИХАЙЛОВИЧ МОРОЗОВНЫ КҮРСӘТӘЛӘР

ӘГЕРҖЕ, 30 декабрь. (ТатТАСС). 29 нчы декабрьдә Әгерҗе депосы эшчеләренең, инженер-техник работникларының һәм хезмәткәрләренең җыелышы булды. Анда 400 дән артык кеше катнашты. Җыелыш Минзәлә сайлау округыннан СССР Верховный Советы депутатлыгына кандидат күрсәтү турындагы мәсьәләне тикшерде.

ВКП(б) ның Әгерҗе район комитеты секретаре иптәш Миңлегалиев җыелышта катнашучыларга сайлау кампаниясенең бурычлары турында кыскача ңечь сөйләп, депо эшчеләрен, инженер-техник работникларын һәм хезмәткәрләрен СССР Верховный Советы депутатлыгына лаеклы кандидат күрсәтергә чакырды. Аннары трибунага Әгерҗе депосының иң яхшы машинисты папавинчы иптәш Захаров күтәрелә. Ул болай ди:

— Мин, СССР Верховный Советы депутатлыгына Минзәлә сайлау округыннан кандидат итеп, большевиклар партиясенең турылыклы улы, дачлыклы чекист, Татарстан АССР ның эчке эшләр халык комиссары иптәш Ефрем Михайлович Морозовны күрсәтергә такдим итәм. Иптәш Морозов, дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча хөкүмәт заданиеләрен уңышлы итеп үтәгәнлеге өчен „Почет билгесе“ордены белән бүләкләнде.

Җыелышта катнашучылар иптәш Захаровның такдимен көчле алкышлар белән каршы алдылар. Аннан соң чыгыш ясаган депо начальнигы Кунцевич, стахановчы Сәйдәшев, мастер Смолин һәм башка иптәшләр иптәш Захаровның такдимен кайнар рәвештә яклап чыктылар.

Җыелыш бер тавыштан түбәндәге карарны кабул итте:

„ССР Союзы Конституциясенең 141 нче статьясе нигезендә, СССР Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп иптәш Ефрем Михайлович Морозовны күрсәтергә һәм Минзәлә сайлау округыннан Милләтләр Советы депутатлыгына тавышка куелуга аның ризалык бирүен сорарга.

Җыелыш Минзәлә округындагы барлык сайлаучыларны иптәш Морозов кандидатурасын якларга һәм сайлаулар көнендә үзләренең тавышларын бердәм рәвештә аңа бирергә чакыра“.

Сайлаулар көнен лаеклы каршылау өчен җыелышта катнашучылар хезмәт дисциплинасын тагын да югарырак күтәрү, поездларны график буенча йөртү, планнан тыш бер паровозга ремонт ясау, 100 тонна ягулыкка экономия ясау һәм башкалар турында үз өсләренә йөкләмәләр алдылар.

Җыелыш округ күләмендәге сайлау алды җыелышына 6 кешедән вәкилләр сайлады.

ТАТАРСТАН АССР НЫҢ БАРЛЫК КОЛХОЗЧЫЛАРЫНА, МТС ҺӘМ СОВХОЗ ЭШЧЕЛӘРЕНӘ, ТРАКТОРЧЫЛАРГА ҺӘМ КОМБАЙНЧЫЛАРГА, ҖИР ОРГАННАРЫ РАБОТНИКЛАРЫНА

Татарстан АССР Әтнә районы авыл хуҗалыгы алдынгыларының мөраҗәгате

Кадерле иптәшләр!

Без күп миллионлы халкыбызның тормышында булачак зур вакыйга алдында торабыз. 1941 нче елның 15 нче февралендә ВКП(б) ның XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе үзенең эшен башлый. Ленин-Сталин партиясенең иң яхшы вәкилләре промышленность һәм транспорт өлкәсендә гаять зур ижад эшенә йомгаклар ясарлар, коммунизмга таба алдагы җиңүле хәрәкәтнең юлларын билгеләрләр.

Большевиклар партиясе һәм бөек Сталин җитәкчелегендәге совет халкы гаять зур социалистик төзелешнең барлык тармакларында елдан-ел яңа җиңүләргә ирешә. Безнең колхозларыбыз да ел саен зур уңышларга ирешәләр. Социалистик игенчелек стахановчылары, дөньяда алдынгы техника белән коралланып, агрономия фәне казанышларыннан һәм гаять бай тәҗрибәдән киң күләмдә файдаланып, табигатьнең кире көчләрен уңышлы рәвештә җиңәләр, торган саен күбрәк иген уңышы яулап ала баралар.

„Авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр“ турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карары колхоз строен тагын да ныгытуның куәтле яңа күтәргече булды. Ул колхозларның һәм колхозчыларның инициативасын тәмам чишеп җибәрде, артельләрне һәр яклап үстерү өчен көрәштә аларның җаваплылык хисен һәм кызыксынуларын арттырды.

Быел безнең районның „Тарлау“ колхозы һәр гектардан уртача 98 пот бөртекле ашлык алды. Ленин исемендәге авыл хуҗалыгы артеле колхозчылары гектарыннан 90 пот бөртекле ашлык алып, югары уңыш алуга ирештеләр. Алдынгы бригадалар, звенолар тагын да югарырак уңыш алдылар. Мәсәлән, Киров исемендәге колхозның 8 нче бригадасы гектарыннан 120 пот уҗым бодае, Ленин исемендәге колхозның 6 нчы бригадасы гектарыннан уртача 103 пот бөртекле ашлык уңышы алдылар. Ленин исемендәге колхозның Биби Шәйхиева звеносы гектарыннан 128 пот, Каганович исемендәге колхозның Фәридә Ханнанова звеносы 117 пот алды. Районда мондый мисальләр аз түгел. Районның барлык колхозлары дәүләткә ашлык, бәрәңге, яшелчә һәм башка төрле авыл хуҗалыгы продуктлары тапшыру йөкләмәләрен үтәделәр.

Ләкин безлә әле артта калучы колхозлар да бар. Быел „Электросталь“ колхозы бер генә чараны да вактында үтәмәде. „Яңа Кишет“, „Кызыл Шахтер“, „Оборона“ колхозлары язгы чәчүне озакка суздылар, чәчүлекләрне начар тәрбияләделәр, урып-җыюны, ашлык сугуны һәм ашлык тапшыруны озакка суздылар. Безнең район МТС ы—республикада артта калучыларның берсе. Аның җитәкчеләре әле бай техникадан тулысынча файдаланмаганнар, алар шунда булган бик яхшы кадрлар турында, аларның эш тәҗрибәсен барлык тракторчыларга, комбайнчыларга күчерү турында аз кайгырталар.

Социалистик авыл хуҗалыгын бер туктаусыз күтәрү өчен без әле гаять бай мөмкинлекләрдән начар файдаланабыз. Мәсәлән, безнең районны алып карыйк. Алдынгы колхозлар барлык агротехника чаралары планнарын үтәсәләр һәм арттырып үтәсәләр, бөтен районны алганда исә эш канәгатьләнерлек булудан ерак тора. 1939 нчы елны туңга сөрү планы бары 67 процентка гына, көл җыю 25,4. кош тизәге җыю 43,6 процентка гына үтәлде. Ашлама өчен торф чыгару буенча план заданиесе яртысыннан аз гына артык үтәлде. Пар җирләрен сөрүгә, камыл лущить итүгә бик аз игтибар бирелде. Болар барсы да быелгы иген уңышына йогынты ясамый калмадылар.

Үзебезнең артта калган аерым колхозларыбызның һәм МТС ларыбызның артта калуларын мөмкин кадәр тизрәк бетерүне, аларны орденлы Татарстанның алдынгылары сафына чыгаруны без үзебезнең алдыбызга иң беренче бурыч итеп куябыз. Без барыбыз да 1941 нче елны һәрбер колхоз һәм МТС Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу хокукын бирә торган күрсәткечләрне намус белән үтәрлек итеп эшләрбез. Татарстандагы барлык колхозчыларны, тракторчыларны, комбайнчыларны, барлык МТС һәм совхоз эшчеләрен дә без шуңа чакырабыз.

Иптәшләр! Хәзер совет халкы 1940 нчы елга йомгаклар ясый. Бөтен илдә партиянең XVIII нче конференциясе хөрмәтенә социалистик ярышның куәтле дулкыны киңәя. Хезмәт ияләре үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алалар. 1941 нче елны социалистик төзелешнең барлык тармакларында яңа производство уңышларына ирешү теләге белән яналар. Бу гүзәл ярышка барыбыз да бер кешедәй булып кушылыйк. Партиянең XVIII нче конференциясен язгы чәчүгә үрнәк булырлык итеп хәзерләнү белән истә калдырыйк. 1941 нче елны стахановча иген уңышын арттырыйк, җәмагать терлекчелеген үстерү планын үтик һәм арттырып үтик, терлекләрнең продукт бирүләрен арттырыйк, авыл хуҗалыгының барлык тармакларының тагын да үсүен тәэмин итик.

Без 1941 нче елны гектарыннан кимендә 100 пот бөртекле культура, 110 пот тары, 1.100 пот бәрәңге, 42 пот җитен орлыгы алуны өстебезгә алабыз. Бу уңышка ирешү өчен барлык тракторларга һәм тагылма инвентарьга вактында һәм бик яхшы итеп ремонт ясарбыз, кимендә 20 мең гектар җирдә кар тотарбыз, басуга 130 мең тонна тирес чыгарырбыз, 15 мең тонна торф һәм 5 мең тонна компост хәзерләрбез, 1 мең тонна көл, 500 тонна кош тизәге җыярбыз. Сабан культураларын иң күбе 6—7 көн эчендә чәчеп бетерербез.

Колхозчылар бу йөкләмәләрне практик эшләр белән беркетәләр. Ленин исемендәге колхоз тирес чыгару буенча еллык планны 79 процентка үтәле инде, кар тотуны, торф һәм компост хәзерләүне, барлык җирле ашламаларны җыюны киң күләмдә җәелдерде. Бөтен районда басуларга барлыгы 30 мең тоннадан артык тирес чыгарылды. Барлык колхозлар югары сортлы орлыклар белән тәэмин ителделәр. Ленин исемендәге, „Трактор“, „Ирек“, „КИМ“ колхозлары һәм күп кенә башка колхозлар авыл хуҗалыгы инвентарена һәм транспортка ремонт ясауны тулысынча төгәлләделәр, орлыкларны триер аркылы үткәрделәр, колхозчыларны укытуны оештырдылар.

Быел без тирес җыюга һәм аннан файдалануга аеруча игтибар бирәбез. Моның өчен һәрбер колхозда гади типтагы тирес саклау урыннары ясалачак. Шулай ук дөрес чәчү әйләнешләре кертү, тирән сөрү, җирләрне культуралы төстә эшкәртү һәм аларны бик яхшылап ашлау юлы белән дә югары һәм ныклы иген уңышы өчен көрәшербез. Чәчүне югары сортлы, сайлап алынган орлыклар белән үткәрербез, чәчүлекләрне үрнәк булырлык итеп тәрбияләүне тәэмин итәрбез.

Бу алынган йөкләмәләрне үтәүгә барлык колхозчыларны, комбайнчыларны һәм тракторчыларны туплярбыз. Даими звенолар оештырырбыз, барлык колхозларны, бригадаларны, звеноларны төгәл төзелгән эш планнары белән тәэмин итәрбез, колхозларда агротехниканы массовый өйрәнүне җәеп җибәрербез. Язга кадәр 55 тракторчы, 21 комбайнчы, 300 звено җитәкчесе, 200 яровизатор, 134 прицепщик хәзерләрбез. Кырчылык бригадалары бригадирларын кыска сроклы курслар һәм семинарлар аркылы үткәрербез.

1941 нче елны без 40 гектар җирдә кырларны саклау өчен агачлар утыртырбыз, аларны саклауны оештырырбыз.

Колхозчы иптәшләр, безнең уңышларыбызның залогы—авыл хуҗалыгы артеле уставын, партиянең һәм хөкүмәтнең колхозлар турындагы барлык карарларын бик нык үтәүдән гыйбарәт. Дисциплинаны барлык чаралар белән ныгытырбыз, хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырбыз, ялкауларга, летуннарга һәм колхоз производствосын таркатучыларга каршы көрәшербез. Штатларны яңадан карап чыгарбыз, колхозларның идарә аппаратын җитез эшли торган һәм арзанлы итәрбез, колхозларда милекне һәм хезмәтне исәпкә алуны яхшыртырбыз, җәмагать милкенә тагын да сагырак карарбыз.

Иптәшләр, ВКП(б) ның XVIII нче конференциясе хөрмәтенә социалистик ярышны кинрәк җәелдерик. Бу ярыштан бер колхоз да һәм совхоз да, бер МТС та, бер колхозчы да, бер тракторчы да, авыл хуҗалыгының бер генә белгече дә читтә калмаска тиеш. Кырларда, фермаларда, колхоз һәм совхоз производствосының барлык тармакларында стахановча эшләп, күргәзмәдә катнашу хокукын яулап алырбыз, илебезнең байлыгын арттырырбыз, социалистик Ватаныбызның көчен һәм куәтен тагын да ныгытырбыз.

Яшәсен Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе!

Яшәсен туганыбыз бөек Сталин!

МӨРАҖӘГАТЬ ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ АЛДЫНГЫ КОЛХОЗЧЫЛАРЫ КИҢӘШМӘСЕНДӘ КАБУЛ ИТЕЛДЕ.

П А Р Т И Я   Т О Р М Ы Ш Ы

Пропаганда эшенә җитәкчелекне тагын да яхшыртырга

Хәзер Чистай районында коммунистлардан һәм партиясез интеллигенциядән үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү өстендә өзлексез һәм җидди рәвештә эшләүче иптәшләрне күпләп санарга була. ВКП(б) ның район комитеты мондый иптәшләр өчен философия, политэкономия һәм тарих фәннәре буенча лекцияләр укуны оештырды. Иптәш Сталинның „Октябрь революциясе һәм рус коммунистларының тактикасы“, „Марксистик диалектик методның төп сызыклары“, „Тарихи материализмның нигезләре“ дигән хезмәтләре, В. И. Ленинның „Материализм һәм эмпириокритицизм“ дигән әсәре турында лекцияләр укылды инде. Ел ахрына кадәр политэкономия һәм СССР халыклары тарихы буенча тагын берничә лекция укылачак.

Күп кенә партоешмалар пропаганда эшенә җитәкчелек итүне сизелерлек яхшырттылар. Чистай шәһәрендәге 2 нче номерлы мәктәп янындагы башлангыч партоешма (секретаре иптәш Остроумова) бу эшкә аеруча яхшы җитәкчелек итә. Партоешма ВКП(б) тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләр белән системалы рәвештә индивидуаль һәм групповой консультацияләр үткәрә, иптәшләрчә беседалар оештыра. Партия җыелышларында пропаганда мәсьәләләре әледән-әле тикшерелә. Бу партоешмада учетта торучы 12 коммунистның 7 се „Кыскача курс“ны үзлекләреннән өйрәнүне тәмамладылар инде. Калганнары да партия тарихын өйрәнү өстендә системалы эш алып баралар.

Вахитов исемендәге колхоз, дәүләт банкысының район бүлеге, судноларга ремонт ясау заводы партоешмалары да пропаганда эше белән шулай ук җидди шөгыльләнәләр, партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләргә көндәлек ярдәм күрсәтәләр.

Соңгы вакытларда безнең районда райкомның җитәкче работниклары, пропагандистлар һәм инструкторлары тарафыннан коммунистлар, бигрәк тә актив белән, теория мәсьәләре буенча индивидуаль беседалар үткәрү практикага кертелде. Мондый беседалар 200 дән артык үткәрелде инде. Бу чара кемнең үз өстендә ничек эшләвен, партия тарихын өйрәнүдә кемнең нинди кыенлыкларга очравын һәм кемгә нинди ярдәм оештырырга кирәклеген белеп торырга мөмкинлек бирде.

Пропаганда эшендә булган кайбер уңышларны күрсәтү белән бергә, бу эштә әлегә кадәр яшәп килгән зур кимчелекләрнең дә барлыгын әйтергә кирәк. Райком ВКП(б) тарихын үзлегеннән өйрәнүчеләргә барлык партоешмаларның да конкрет җитәкчелек итүләрен тәэмин итә алмады. Бу — җитешсезлекләрнең иң зурысы. Кайбер партоешма секретарьлары, аерым алганда Водторгтранс партоешмасы секретаре Дурандин, агач заводы партоешмасы секретаре Матвеев иптәшләр, пропаганда эше белән тиешенчә шөгыльләнмиләр, коммунистларның теоретик укулары турында аз гына да кайгыртучанлык күрсәтмиләр, аларның үз өсләрендә ничек эшләүләрен тикшермәү генә түгел, хәтта мондый контрольне бөтенләй кирәксез саныйлар. Бу зарарлы караш бетерелергә тиеш. Коммунистлар белән мөмкин кадәр ешрак беседалар оештырырга, аларның үз өсләрендә ничек эшләүләрен белеп торырга кирәк.

Бездә әле партия тарихын аз гына да өйрәнмәгән, яки „Кыскача курс“ ның 1 нче һәм 2 нче бүлекләрендә утыручы, күп беләм дип сөйләнеп тә, бер нәрсә дә белмәүче коммунистлар да аз түгел. Мебель фабрикасы директоры Асантьев, райпотребсоюз председателе Шашин, район советының юл төзү бүлеге мөдире Җамалетдинов иптәшләр үзләрен әнә шулай күрсәтәләр. Ә беседа вакытында элементарь сорауларга да ачык җавап бирә алмыйлар.

Партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләргә лекцияләрнең зур ярдәм итүләре турында күп сөйләнә. Ләкин аннан тиешенчә файдалана белмәүчеләр дә бар. Кайберәүләр „лекциягә йөри“ дисеннәр өчен генә вакытларын уздырып кайталар. Мәсәлән, ярма заводының транспорт начальнигы иптәш Садыйков лекцияләргә бик еш йөри, ләкин бер кайчан да аларны игтибар биреп тыңламый һәм шуңа күрә бер нәрсә дә аңламыйча кайтып китә.

ВКП(б) ның район комитеты коммунистларның соравы буенча актив өчен кичке урта мәктәп оештырды. Бу бик кирәкле һәм мөһим чара иде. Бу мәктәпне оештыруны, барыннан да бигрәк, Григорьев, Мостафин, Сиротин һәм Баев иптәшләр сорадылар. Ләкин мәктәптә занятиеләр башлангач та, шушы ук иптәшләр укырга йөрмәделәр. Коммунистларның мондый дисциплинасызлыгына чик куелырга тиеш. Коммунист кеше үзенең белемен күтәрү өчен барлык мөмкинлекләрдән дә файдаланырга тиеш.

Пропаганда эшендәге бу кимчелекләрне бетерү өчен безнең районда мөмкинлекләр бар һәм көчләр дә җитәрлек. Бары тик партоешмаларның һәм пропаганда работникларының тагын да тырышыбрак эшләүләре, һәрбер коммунистка индивидуаль якын килә белүләре генә таләп ителә. Барлык коммунистларның да революцион теорияне яхшы үзләштерүләренә ирешү өчен, алар алдында устав нигезендә ныклы таләпләр куярга, үзенең белемен күтәрергә теләмәүчеләргә карата партия җәмәгатьчелеге фикерен тупларга кирәк. Шул вакытта пропаганда эшендә булган бу кимчелекләр, һичшиксез, бетерелер һәм җитәкче работникларның теоретик артталыкларын бетерүгә, партияле һәм партиясез кадрларыбызның идея - политик дәрәҗәләрен тагын да күтәрүгә ирешербез.

М. Калмыков.

ВКП(б) ның Чистай райкомының кадрлар буенча секретаре.

ХУҖАЛЫКЧЫЛАР ҺӘМ ПАРТОЕШМА СЕКРЕТАРЬЛАРЫ КИҢӘШМӘСЕ

ВКП(б) ның Сталин райкомы шушы көннәрдә районнардагы предприятие директорларының, баш инженерларының, техноругларының һәм партия оешмалары секретарьларының киңәшмәсен үткәрде. Вахитов исемендәге [illegible] директоры иптәш Логинов, энергокомбинатның баш инженеры Кузовкин, мехкомбинат партбюросы секретаре Кузьмин һәм 4 нче ясалма каучук заводы партбюросы секретаре Федоров иптәшләрнең информацияләре тыңланды. Алар үз предприятиеләренең эше, 1941 нче елның производство программасын үтәү өчен хәзерлек һәм партия оешмасы тарафыннан билгеләнгән чаралар турында сөйләделәр.

Жиркомбинат директоры иптәш Логинов 1940 нчы елны комбинат буенча планның үтәлмәвен әйтте. Комбинат җитәкчеләре СССР Верховный Советы Президиумының 26 нчы июнь һәм 10 нчы июль Указларын үтәү өчен көрәшне йомшак оештырганнар, [illegible]. План үтәлмәүнең төп сәбәбе әнә шунда.

Энергокомбинат үткән елга караганда быел яхшырак эшләгән. Электр энергиясенә һәм ягулыкка экономия ясауга ирешкән. Ләкин комбинат эшендә кимчелекләр дә бар әле. Анда аварияләр әле дә бетерелмәгән.

Фикер алышуларда катнашучылар партиянең XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе исемендәге социалистик ярышның предприятиеләрдә киң колач алуы, эшчеләр коллективларының зур энтузиазм белән ярышып эшләүләре турында күп кенә фактлар китерделәр.

Г. Масаутов.

Индивидуаль беседалар яхшы нәтиҗәләр бирә

Партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүче иптәшләр белән үткәрелә торган индивидуаль беседалар партия пропагандасы эшенә җитәкчелек итүнең иң әһәмиятле [illegible]. Мондый беседалар коммунистларның үз өсләрендә ничек эшләүләрен, аларга нинди ярдәм кирәклеген белеп торырга мөмкинлек бирә, [illegible] вакытында ук, аңлашылмаган моментлар да хәл кылына.

Бу эшне без башта райкомның [illegible] башладык. [illegible] 300 дән артык [illegible] индивидуаль беседа үткәрелде. [illegible] 1.206 кешегә индивидуаль консультация бирелде. Партия пропагандасы эшенең башка төрләре белән берләштереп үткәрелгән бу эш, [illegible] катнашучыларның саны 170 тән артык инде.

Безнең районда партия активы гына түгел, бәлки партиясез иптәшләр дә индивидуаль консультацияләргә һәм беседаларга зур кызыксыну белән йөри башладылар. Партиясез иптәшләрдән Телешев, Ребровский, Садыйков һ. б. иптәшләрнең райкомга [illegible].

Районның башлангыч партоешмаларының секретарьлары да бу эшкә күбрәк игтибар бирә башладылар. [illegible] Юнусов [illegible]. Шулай итеп монда, [illegible]. Бу оешмада партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләр 30 кеше исәпләнә. Шуларның 17 се хәзер инде „Кыскача курс“ның 12 бүлеген дә өйрәнүне тәмамладылар. Сибгатуллин, Нигмәтҗанов, Хәсәнова иптәшләр теоретик белемнәрен тагын да тирәнәйтү өстендә үрнәкле эш алып баралар.

Галәветтинов.

Апас райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире.

МАТБУГАТ КҮЗӘТҮ

„КОЛХОЗ“ ГАЗЕТАСЫ ҺАМАН ДА ИСКЕЧӘ ЭШЛИ

ВКП(б) Үзәк Комитетының „Район газеталары турында“ гы карары чыкканнан соң 4 ай вакыт үтте. Бу вакыт эчендә күп кенә район газеталары үзләренең эшләрен үзгәртеп кору буенча шактый эшләр башкардылар. Ләкин, карардан соң да борылыш ясамаучы, һаман да искечә эшләүче газеталар да аз түгел әле. ВКП(б) ның Баулы райкомы һәм хезмәт ияләре депутатларының район советы органы булган „Колхоз“ газетасын алып карыйк. ВКП(б) Үзәк Комитеты карары чыкканнан соң үткән вакыт эчендә редакциядән тыш авторларның материаллары күбрәк урнашу, редакция работникларының, ТАСС, ТатТАСС материалларының һәм башка официаль материалларның бер кадәр кимү факты бар, әлбәттә. Ләкин, редакциянең эшендә әле дә булса кискен борылыш юк.

Авторлар туплау һәм алар белән системалы рәвештә эш алып бару буенча редакция бер нәрсә дә диярлек эшләмәгән. Шуның нәтиҗәсе буларак, редакциягә килә торган хатларның саны ВКП(б) Үзәк Комитеты карары чыкканнан соң үткән чорда артмаган гына түгел, бәлки кимегән. Мәсәлән, июнь аенда редакциягә 73, июль аенда 94, август аенда 113 материал килгән булса, сентябрь аенда 91, октябрь аенда 55, ноябрь аенда 50 гә якын гына хәбәр килгән. Уртача алганда редакциягә көненә бары тик 1, 2 материал гына килгән дигән сүз. Бу факт үзе генә дә „Колхоз“ газетасының (редакторы иптәш Низаметтинов) редакциядән тыш авторлар белән бер төрле дә эш алып бармавын бик ачык күрсәтә.

„Колхоз“ газетасының райондагы кайбер колхозлар белән бөтенләй элемтәсе булмавы, совхоз тормышын үзенең битләрендә бөтенләй диярлек яктыртмавы—редакция работникларының урыннар белән җитәрлек бәйләнештә булмауларын һәм редакциядән тыш актив белән планлы эш алып бармауларын бөтен тулылыгы белән раслый.

„Колхоз“ газетасы күп кенә актуаль мәсьәләләрне үзенең битләрендә җитәрлек яктыртмый. Мәсәлән, ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының колхозларда җәмәгать терлекчелеген үстерү турындагы карары нигезендә газета үзенең битләрендә бу мәсьәләне туктаусыз яктыртып барырга, аны тормышка ашыру өчен барлык чараларны күрергә тиеш иде. Ләкин „Колхоз“ газетасы битләрендә терлекчелек мәсьәләләре бик аз һәм бик өстән генә яктыртыла. Шулай ук, ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының „Авыл хуҗалыгы продуктларын сатып алу һәм хәзерләүләр политикасындагы үзгәрешләр“ турындагы карары нигезендә дә редакция системалы эш алып бармый, бу мөһим мәсьәлә буенча газетада очраклы рәвештә генә язылa.

СССР Верховный Советы Президиумының 26 нчы июнь Указын тормышка ашыру буенча газеталарның туктаусыз эш алып барырга тиешлекләре бик ачык нәрсә. Ләкин, „Колхоз“ газетасы бу мәсьәләдән бөтенләй диярлек читтә тора. Җиде көнлек эш атнасына, сигез сәгатьлек эш көненә күчү, эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең предприятие һәм учреждениеләрдән үз белдекләре белән китүләрен тыю турында ВЦСПС мөрәҗәгатен һәм СССР Верховный Советы Президиумының шул мәсьәлә турындагы 26 нчы июнь Указын „Колхоз“ газетасының бөтенләй басмый калдыруын нәрсә белән аңлатырга? Моны тик газетаның җаваплы редакторы иптәш Низаметтиновның политик сукырлыгы белән генә аңлатырга мөмкин. Бәлки газета үзенең бу зур хатасын эш практикасында төзәткәндер? Кызганычка каршы, андый эш тә булмаган. Указ чыкканнан алып шушы көнгә кадәр „Колхоз“ газетасы битләрендә бу мәсьәләгә карата 2—3 материал гына урнашкан булу моны ачык күрсәтә.

Газетада баш мәкаләнең роле гаять зур. Баш мәкалә теге яки бу мәсьәлә буенча юнәлеш бирергә тиеш. Баш мәкаләләрне карап чыгу белән газетаның күбрәк нинди мәсьәләләрне яктыртуы яисә яктыртмавы бик ачык күренә. „Колхоз“ газетасы 1940 нчы ел эчендә авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә карата 16, партия тормышы мәсьәләре буенча—6, пропаганда мәсьәләләре буенча—2, оборона мәсьәләре буенча—2, финанс мәсьәләләренә карата 1 баш мәкалә биргән, калган баш мәкаләләр төрле кампанияләргә карата язылганнар.

Димәк, баш мәкаләләрнең күпчелеге авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә карата язылганнар. Бу, әлбәттә, шулай булырга тиеш. Ләкин, безнең гаять зур дәрәҗәдә бай тормышыбызны аерым мәсьәләләр белән генә чикләп калдырырга ярамый. Аның барлык якларын яктырту район газеталарының да төп бурычы булып тора. „Колхоз“ газетасында уку өйләре, клублар, көтепханәләр, укый-яза белмәүчелекне бетерү мәсьәләренә, мәктәп тормышына, балаларны коммунистик тәрбияләү мәсьәләләренә карата баш мәкаләләрнең булмавы газетаның культура мәсьәләләрен үзенең битләрендә яктыртуга тиешенчә әһәмият бирмәвен күрсәтә. Шулай ук, газета совет төзелеше буенча, сәламәтлек саклау буенча, районның төзеклеге өчен көрәш мәсьәләләре буенча да баш мәкаләләр бирмәгән. Хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү—хезмәткә һәм җәмәгать милкенә социалистик караш рухында тәрбияләү, кешеләрнең аңында капитализм калдыкларына каршы көрәш мәсьәләләренә карата урындагы конкрет материалларга таянып язылган баш мәкаләләр, һичшиксез, кирәк иде. Ләкин без аларны „Колхоз“ газетасы практикасында күрә алмыйбыз.

Югарыда күрсәтелгән җидди кимчелекләрне бетерү буенча „Колхоз“ газетасы барлык чараларны күрергә тиеш. ВКП(б) ның Баулы райкомы үзенең газетасына конкрет ярдәм итүне һәм көндәлек контроль булдыруны көчәйтер, дип ышанабыз.

РАЙОН ГАЗЕТАЛАРЫННАН

— ВКП(б) райкомы бюросы үзенең соңгы утырышында Разин исемендәге колхозда, „Байкал“ һәм „Арсенал“ колхозларында 1941 нче елның язгы чәчүенә хәзерлекнең торышы турындагы мәсьәләне тикшерде. Райком бюросы бу колхозларда язгы чәчүгә хәзерлекнең канәгатьләнмәслек булуын күрсәтте һәм аларда эшне яхшырту өчен конкрет чаралар билгеләде.

(„Яңа юл“ газетасы, Буа районы).

— ВКП(б) райкомы партия кандидатларының район киңәшмәсен үткәрде. Киңәшмәгә партия кандидатларыннан 56 кеше катнашты. Анда ВКП(б) райкомы пропагандисты иптәш Дәүләтшин „Партия коммунисттан нәрсә таләп итә“ дигән темага доклад ясады.

(„Кызыл Армиячә“ газетасы, Кызыл Армия районы).

— Киров исемендәге колхозда стахановчылар мәктәбе оештырылды. Мәктәпнең 6 занятиесе булды инде. Занятиеләргә 157 кеше катнашты.

(„Социализм Юлы“ газетасы, Әтнә районы).

Авыл мәктәбенең иң әһәмиятле бурычы

Социалистик төзелешнең гомуми бурычларыннан һәм мәктәпне политехникалаштыру турында, укытуны файдалы хезмәт белән бергә бәйләү турында партиябезнең күрсәтмәләреннән чыгып, иптәш В. М. Молотов партиябезнең XVIII нче съездында мәктәп балаларын киләчәктәге практик эшкә беркадәр хәзерләү бурычын куйган иде. Иптәш Молотов болай диде:

«Урта мәктәпне тәмамлап чыгучы һәм күпчелек хәлләрдә теге яки бу практик эшкә китүче гаять күп сандагы егетләр һәм кызлар урта мәктәпне тәмам итү алдыннан инде киләчәк практик эшләренә һич югында беркадәр хәзерлек алсыннар иде, дигән мәсьәлә килеп баса».

Шушы елның 26 нчы августында РСФСР Наркомпросы авыл мәктәбенең эшен яхшырту чаралары турында приказ чыгарды. Приказда авыл мәктәбен үзгәртеп коруның программасы бирелә. Авыл мәктәбе социалистик игенчелек практикасы белән иң якын элемтәдә булырга һәм укучыларны киләчәктәге практик эшкә хәзерләргә тиеш. Приказ авыл хуҗалыгы буенча практик занятиеләр һәм экскурсияләр үткәрүне, әлбәттә, кертүне күздә тота. Бу занятиеләр һәм экскурсияләр укучыларны авыл хуҗалыгы үсемлекләренең биологиясе белән, агротехника белән, колхозларның, совхозларның, терлекчелек фермаларының һәм МТС ларның казанышлары белән таныштырырга тиешләр.

Безнең республикабызда партиянең һәм хөкүмәтнең бу гаять әһәмиятле директивасын тормышка ашыручы мәктәпләр бар. Ләкин аларның саны бик аз әле. Шулай да алар турында әйтеп үтү бик файдалы булачак.

Мәсәлән, Кайбыч районы, Ульянково урта мәктәбендә яшь натуралистлар түгәрәгендә 50 укучы 1936 нчы елдан бирле метеорология күзәтүләре алып баралар. Укучылардан В. Трущин, А. Морфин, А. Углов һәм башкалар үзләренең теоретик белемнәрен колхоз участкысында эшләүдә кулланалар. В. Разин һәм К. Ветлугиннар Кызыл Армия өчен атлар тәрбияләп үстерәләр.

Теләче районының Янсуар урта мәктәбе укучылары җимеш бакчасы оештырганнар. Шулай ук анда яшь натуралистлар түгәрәге эшли. Аларның эш тематикасы колхозга бик нык бәйләнгән. Күп кенә укучылар, мәсәлән, К. Карабудаев, А. Ильина, С. Чумаров, А. Писарев, Александров, Абрамов һәм башкалар җәйге айларда колхозда 150 шәр хезмәт көне эшләгәннәр һәм шуның өстенә мәктәп яны участкысында эшләүне дә ташламаганнар. Бу мәктәпнең 7 классын бетергән Борис Николаев инде «Дружба» колхозының председателе булып эшли.

Минзәлә урта мәктәбенең биология укытучысы иптәш Чувакин авыл хуҗалыгы станциясе янында укучылар өчен практик эш оештырган. Укучылар үз эшләреннән оештырылган күргәзмәдә үзләренең ничек итеп гектарыннан 400 центнер чөгендер, 77 центнер помидор, 300 центнер кабак, 5 центнер кавын алганлыкларын күрсәттеләр. Үзенең 20 квадрат метр зурлыктагы участкысында 120 килограмм чөгендер уңышы алган Вера Курунова 1941 нче елгы Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә кандидат итеп билгеләнде.

Күп кенә мәктәпләрнең укучылары яшь терлекләрне шефлыкка алалар, авыл хуҗалыгы машиналары үрнәкләре ясыйлар, үсемлекләрнең яңа сортларын үстереп чыгаралар. Тулы булмаган саннарга караганда, авыл мәктәпләрендә укучылардан 39 кеше инде 1941 нче елгы күргәзмәгә кандидат итеп күсәтелгәннәр.

Ләкин мондый мисальләр әле массовый төс алмаганнар. Күп кенә мәктәпләр әле колхоз тормышыннан аерылганнар, колхоз авылыннан читтә торалар.

Нәтиҗәдә тулы булмаган урта һәм урта мәктәпне тәмам иткән кешене еш кына аз белемле колхозчыдан аерып булмый. Ул колхозда учет эше алып бара алмый, гомуми җыелыш протоколын яза алмый, җир үлчи белми, терлекчелек һәм агротехника буенча киңәшләр бирә белми, авыл хуҗалыгы машинасын йөртә белми. Болар барсы да ботаника курсында озак вакытлар буена лишайникларны гына, зоология курсында амебаны гына өйрәнүдән һәм бодай, сыер, йорт кошлары турында бөтенләй диярлек бер нәрсә дә белмәүдән килеп чыгалар. Математиклар җир мәйданын ничек үлчәргә, бинаның кубатурасын, силос чокырының сыйдырышын исәпләп чыгарырга өйрәтмиләр. Химиклар бакыр купоросы эремәсен тимер чиләктә сакларга ярамаганлыкка өйрәтмиләр. Тел укытучылар һәрбер кешегә кулланырга кирәк була торган эш кәгазьләрен ничек язарга кирәклекне күрсәтмиләр.

Мондый мәктәпләр һәм укытучылар колхозларның практик эшеннән аерылганнар, алар колхоз производствосы интереслары белән яшәмиләр һәм колхозларның сорауларына җавап бирмиләр. Алар үзләренең эшләрендә авыл хуҗалыгы алдынгыларының, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашкан кешеләрнең уңышларын кулланмыйлар.

Үзләренең эшләрен үзгәртеп кору ягыннан авыл мәктәпләренең бурычлары нәрсәдә соң?

Барыннан да элек мәктәптә практик занятиеләр оештырырга кирәк. Мәсәлән: лаборатория эше, колхоз практикасына кагылышлы мәсьәләләрне хәл итү, мәктәп яны участкысында, җанлы почмакта, колхоз, совхоз, МТС лабораторияләрендә, укучының үз семьясенең каралты яны участкысында күзәтүләр һәм тәҗрибәләр, авыл хуҗалыгы машиналарында практик эш, җир үлчәү күнегүләре һәм башкалар. Бу эшләр барсы да биология, химия, физика, математика, география һ. б. курсларның бер өлеше итеп үткәрелергә тиеш.

Хәзерге программалар һәм укыту планнары бу әһәмиятле чараны үткәрү өчен бөтен мөмкинлекләрне бирәләр. Тиз санарга, счетлардан файдаланырга өйрәтү башлангыч мәктәп программасында ук күздә тотыла бит. Урта мәктәптә инде бу арифметиканы, алгебраны һәм геометрияне өйрәнгәндә тагын да тирәнәйтелергә тиеш. 5 нче классларда укучылар счетларда күп билгеләрдән тора торган саннарны куша һәм ала беләләр; авыл хуҗалыгы материаллары буенча процентлар исәпләү өчен таблицалар төзи беләләр; приход - расход ведомстен исәпли беләләр; җиңелчә генә смета төзи беләләр; иген уңышын, эш көчләре санын, хезмәт көннәрен исәпли беләләр. 6 нчы класста инде транспортирдан, астролябиядән файдалана белүгә, еракларгы әйберләргә кадәр булган ераклыкны билгели белергә һ. б. өйрәтергә кирәк. Мондый мисальләрне барлык фәннәр буенча һәм барлык класслар өчен китерергә мөмкин. Мәктәп яны участкыларын ни өчен барлык мәктәпләр дә оештырмыйлар? Анда укучылар авыл хуҗалыгы хезмәте буенча күнегүләр ала алырлар иде, агрономия нигезләрен өйрәнерләр иде. Шулай ук ни өчен физика, геология һ. б. түгәрәкләр оештырмаска? Ни өчен авыл хуҗалыгы хезмәтен, үсемлекчелекне, терлекчелекне өйрәнүгә юнәлдерелгән экскурсияләрне арттырмаска?

Болар барсы да эшләнергә тиеш. Тик барлык практик эшләр нигездә уку вактында үткәрелергә һәм алар укытучының укыту һәм эш планында, мәктәпнең расписаниесендә күренергә тиешләр. Экскурсияләрне барлык фәннәр буенча һәм кырга яки МТС ка гына түгел, бәлки авыл советына, район финанс бүлегенә, район җир бүлегенә, тимер юл станциясенә дә ясарга мөмкин. Экскурсияләр чын тормышны күрсәтәчәкләр.

Тел һәм әдәбият, тарих һәм Конституция укытучылар да бу эшне оештыра алалар. Әгәр дә тел укытучысы укучыларны эш кәгазьләре, протоколлар язарга өйрәтсә, — бу зур уңыш булыр иде! Бу укучыларны үзлекләреннән эшләргә өйрәтер иде.

Түгәрәкләрнең — ботаниклар, бакчачылар, кырчылар, терлекчеләр түгәрәкләренең, яшь терлекләрне, фермаларны шефка алу түгәрәкләренең, авыл хуҗалыгы машиналарын, тракторларны сөючеләр, шоферлар һ. б. түгәрәкләрнең эшен барлык чаралар белән үстерергә һәм ныгытырга кирәк.

Бу эшкә укучыларның ата-аналарын, авыл хуҗалыгы белгечләрен, тәҗрибәче колхозчыларны тартырга кирәк. Түгәрәк эшенең тематикасын программада әйтелгәннәр белән генә чикләмәскә кирәк.

Педагогия институты һәм училищеләре үзләренең эшләрен, бигрәк тә практик эшләр һәм укыту методикасы ягыннан, совет мәктәбенә карата куелган яңа таләпләргә туры китереп үзгәртеп корырга тиешләр.

Бу нәрсә тагын укытучыларның үзләренең хәзерлекләренә дә бәйләнгән. Һәрбер укытучы үзенең белемен арттыру өстендә тырышып эшләргә һәм үз колхозының тормышын белергә тиеш.

Халык мәгарифе бүлекләре мәктәпнең эшен үзгәртеп коруда укытучыга, мәктәп директорына булышлык итәргә тиешләр.

Укытучыларның январь аенда булачак район киңәшмәләрендә мәктәпләрнең укучыларны практик эшкә хәзерләү буенча үзләренең эшләрен ничек итеп үзгәртеп корулары турындагы мәсьәлә тикшерeләчәк. Халык мәгарифе органнарының бурычы бу киңәшмәләрне иң яхшы мәктәпләрнең һәм укытучыларның тәҗрибә алмашуларына әйләндерүдән гыйбарәт.

Ф. Зимуров

ВКП(б) Өлкә Комитетының культура һәм агарту секторы мөдире.

Иртәгә кышкы каникуллар башлана

НӘТИҖӘЛЕ ЯЛДАН СОҢ ТАГЫН ДА ЯХШЫРАК УКЫРГА!

Орденлы Татарстанның пионерлары һәм укучылары!

Ярты ел буе тырышып эш алып барганнан соң шат һәм күңелле ял итү көннәре—кышкы каникуллар башлана.

Безнең социалистик Ватаныбыз хезмәт ияләренең балалары большевиклар партиясенең, Совет хөкүмәтенең һәм иптәш Сталинның үзенең игътибары һәм мәхәббәте белән чолганып алынганнар.

Мәктәпләрдә быелгы каникуллар вакты партиянең XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясенә хәзерлек белән бер вакытка туры килә. Сезнең ата-аналарыгыз һәм туганнарыгыз бу конференцияне производствода социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдереп, югары күрсәткечләр белән каршыларга хәзерләнәләр. Сез дә, социалистик тәэлешнең алдынгыларының үрнәге буенча, уку елының соңгы яртысын иң яхшы үткәрү буенча XVIII нче партконференция исемендәге социалистик ярышка кушылырга тиешсез.

Һәрбер пионер һәм укучы үзенең ял вактын дөрес оештырырга тиеш. Оешкан рәвештә чаңгыда йөрүләр, художество үзешчәнлеге концертлары, физкультура ярышлары, шахмат-шашка турнирлары, кинога, театрларга йөрүләр, музейларга экскурсияләр оештырырга кирәк.

«Пионерская Правда» газетасы тарафыннан бөтен Союз күләмендә оештырыла торган хәрби уенда катнашу—сезнең иң мактаулы бурычыгыз. Оборона халык комиссары Советлар Союзы маршалы иптәш Тимошенконың бу хәрби уенга гаять зур бәя биреп һәм барлык укучыларны анда актив катнашырга чакыруын онытмаска кирәк. Бу уен сездә чын совет гражданы сыйфатлары: батырлык, чыныкканлык һәм каршылыкларны җиңеп чыгу тәрбияли.

Сез көчле, инициативалы һәм хезмәт яратучы булып үсәргә тиешсез. Көндәлек эшләрнең барсында да—зурларында да, кечкенәләрендә дә әнә шундый сыйфатларны тәрбияләргә кирәк. Мәктәпләрдә быел кышкы каникулларга хәзерлек һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты балаларның бурычларын иң ачык итеп билгеләде. Каникуллар вакытында балалар ял итү һәм күңел ачу белән беррәттән, эш тә алып барырга тиешләр. Ял эш белән бергә бәйләп, каникуллар вакытында сез чаңгыда һәм конькида йөрү күнегүләре ала аласыз, ату һәм граната ыргытуның төп кагыйдәләре белән таныша аласыз, танклар, орудиеләр һәм самолетлар модельләре ясарга өйрәнә аласыз.

Авыл мәктәпләрендә укучылар!

Югарыда күрсәтелгәннәр өстенә, сез колхозда уку өе яки кызыл почмакны җиһазлауда катнаша аласыз, чәчлек орлыкларын сынау эшендә колхозга булышлык итә аласыз, кар тотуга хәзерлек эшләрендә катнаша аласыз, яшь терлекләрне шефка алып, аларны тәрбияләүдә зур ярдәм күрсәтә аласыз.

Каникуллар вактын чын магнәсе белән ял итү, нәтиҗәле күнегүләр алу, сәламәтлекне-тазалыкны тагын да ныгыту өчен бөтен күләме белән файдаланырга кирәк.

Педагоглар, пионер вожатыйлар, комсомолецлар һәм ата-аналар!

Сез укучыларның каникулларын иң яхшы итеп оештырырга тиешсез. Пионерлар һәм укучылар, яхшы ял иткәннән соң, уку елының икенче яртысында отлично укуга хәзер булсыннар.

Т. Мөэминев.

Татарстан АССР мәгариф халык комиссарының урынбасары.

2 нче номерлы мәктәпнең (Казан) I нче классында укучы Вил Хәкимов елка сатып ала.

И. Галиев фотосы.

Сулда—Әгерҗе районының Сталин исемендәге авыл хуҗалыгы артеле члены Х. Разиевның балалары—Мусавир һәм Минвар өйләрендә дәрес хәзерлиләр; уртада—Молотов районындагы 16 нчы номерлы мәктәп пионерлары (Казан) тәнәфес вактында III нче „б“ классында укучы Ихсанованың биюен карыйлар; унда—Молотов районындагы балалар музыка мәктәбе директоры иптәш Поляков отличнога укучы Муля Гобәйдуллина, Ира Травина, Оля Егорова һәм Яша Липкиндлар белән нота буенча музыка дәрсе үткәрә.

И. Галиев һәм В. Лаврентьев фотосы.

МИН КОМАНДИР БУЛЫРГА ТЕЛИМ

Мин узган елны мәктәпнең 8 нче классын отличнога тәмамладым. Быел да алдынгыларның берсе булу өчен бөтен энергиямне биреп көрәшәм. Математика, физика фәннәрен бигрәк тә яратып укыйм. Физика буенча күп кенә тәҗрибәләр ясыйм. Хәзерге көндә лампалы радиоалгыч ясау өстендә эшлим, Морзе әлифбасын өйрәнәм. Мин физкультураны да яратам. Каникул көннәрендә хәрбиләштерелгән чаңгы ярышларында катнашачакмын.

Мәктәпне тәмам иткәч, Кызыл Армия сафларына барачакмын. Командирлыкка укырга һәм бөтен гомерем буена Кызыл Армиядә хезмәт итәргә телим. Шунлыктан, „Спартак“ спорт җәмгыятендә ат өстендә йөрергә өйрәнеп, „Ворошиловча атлы“ значогын алуга ирештем.

Рифгат Нәзиров.

Сталин районындагы 90 нчы номерлы мәктәпнең 9 нчы классында укучы.

ТЫРЫШСАҢ, АҢЛЫЙСЫҢ

Мин узган ел мәктәпнең 4 нче классын отличнога тәмам иттем. Быел да 5 нче класста отличнога укып киләм. Мин дәресләрне калдырмыйм. Мәктәптән кайткач, бераз ял итәм, урамга чыгып саф һавада йөрим, аннары дәрес хәзерләргә керешәм.

Дәресләрне яхшы үзләштерү өчен өйдә һәр көн 3—4 сәгать укырга туры килә. Мин рус телен һәм география фәнен аеруча яратып укыйм. Безнең укытучыбыз Григорьев географияне бик яхшы итеп аңлата.

Әти заводта эшли, әни кечкә мәктәптә укый. Шунлыктан, күп вакыт дәресләрне үзлегемнән хәзерләргә туры килә. Кайбер дәресләрне аңлау баштарак кыен шикелле булып күренсә дә, тырыша төшкәч, аңлыйсың.

Укуда арттарак калып баручы кайбер иптәшләремә дә булышлык күрсәтәм. Мин җәмәгать эшләрендә дә катнашам: пионерлар отрядында эшлим һәм стена газетасы чыгаруга булышам.

Маргарита Коган.

Бауман районындагы 11 нче номерлы урта мәктәпнең 5 нче классында укучы.

УКУ ЕЛЫН УҢЫШЛЫ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН

Мәктәпләр уку елының беренче яртысын йомгаклау өстендә эшлиләр.

Башлангыч маглүматлар өлгерешне күтәрүдә II нче чирекнең уңышлы нәтиҗәләр биргәнлеген күрсәтәләр.

Сталин районы мәктәпләре II нче чиректә партиянең Сталин район комитетының мәктәпләрдә укыту-тәрбия эшләре сыйфатын күтәрүгә карата чыгарган карарын үтәү нигезендә эш алып бардылар.

Мисаль өчен 35 нче урта мәктәпне алып караган вакытта, уку елының II нче чиреген мәктәп аерым фәннәр һәм класслар буенча уңышлы гына йомгаклый. Рус теле, татар теле, география, СССР Конституциясе фәннәре буенча нәтиҗә аеруча яхшы.

II нче чирек тәмамлану уңае белән үткәрелгән контроль эшләр моны тулысынча раслый. Мәсәлән, VII нче классларда татар теленнән контроль диктант буенча өлгереш 91—94 процент тәшкил итә. Менә шушы санның 50—60 проценты яхшы билгеләреннән тора. Рус теленнән булган диктантлар да шундый нәтиҗәләрне бирделәр.

Бу, әлбәттә, контроль эшләрнең шундый нәтиҗәләре белән чикләнергә мөмкин дигән сүз түгел. Безнең илдә, бигрәк тә өченче бишьеллыкта укыту-тәрбия эшенә гаять зур игътибар бирелә. Нәтиҗәләрне көннән-көнгә, атнадан-атнага, айдан-айга яхшырта бару өчен укытучылардан зур хәзерлек, инициатива, иҗад көче таләп ителә.

Партиянең XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясен каршылау уңае белән, мәктәпләрдә бөтен эшне яхшыртуда, дәресләрне политик тотнаклы, эчтәлекле итеп алып баруда, социалистик ярышны җәелдерүдә укытучылар иң зур активлык һәм оешканлык күрсәтергә тиешләр.

21 нче номерлы мәктәпнең (Казан) V нче „а“ классында укучы Рәшидә Баһаветтинова һәм Фәүзия Зәбирова үзара социалистик ярыш договорының үтәлешен тикшерәләр.

И. Галиев фотосы.

Балаларга төпле белем бирү белән бергә, күңелле һәм файдалы ял оештыруга нык игътибар итәргә кирәк. Кышкы каникуллар вактын нык план нигезендә, нәтиҗәле итеп оештыру—гаять әһәмиятле эш. Шунлыктан, каникулларның яхшы үткәрелүе белән бөтен совет җәмәгатьчелеге, иң беренче чиратта укучыларның ата-аналары кызыксынырга тиеш.

Ял вактын—кышкы каникулларны чын магнәсе белән иң яхшы итеп үткәрү—ул, уку елының соңгы яртысын уңыш белән тәмамлау өчен кирәкле шартларның берсе.

Б. Аитова.

Татарстан АССР ның атказанган укытучысы.

КҮҢЕЛ БИРЕП УКЫРГА КИРӘК

Мин мәктәптә рус телен, әдәбиятны, шулай ук башка фәннәрне аеруча яратып укыйм. Дәресләрне күңел биреп тыңлыйм, өйгә бирелә торган заданиеләрне һәр вакыт үтим, дәресләргә яхшы хәзерләнеп киләм.

Мин рус классикларыннан Пушкин, Лермонтов, Л. Толстой, М. Горький һәм башкаларның әсәрләрен бик яратып укыдым һәм хәзер дә укыйм. Мәктәптә барлык фәннәр буенча сынауларны отличнога тапшырып киләм. Узган елгы 8 нче классны тәмам иткән вакытта мине грамота белән бүләкләделәр.

Мәктәптә уку белән бергә, җәмәгать эшләрен дә онтырга ярамый. Мин мәктәп янындагы комсомол комитеты члены булып эшлим. Мин физкультураны да бик яратам. Мәктәптән кайтканнан соң кичләрен „Спартак“ спорт җәмгыятенә барып гимнастика һәм хәрби уеннар өйрәнәм.

Суфия Нугайбекова.

Бауман районындагы 6 нчы номерлы мәктәпнең 9 нчы классында укучы.

ЯХШЫ ЯЛ

Белинский исемендәге 19 нчы номерлы урта мәктәпнең (Казан, Молотов районы) 10 нчы „б“ классында укучы комсомолка Нина Лейбова алдынгыларның берсе. Ул узган ел сынауларны отлично һәм яхшы билгеләренә тапшырган. Ике елдан бирле пионерлар вожатые булып эшли. Н. Лейбова кышкы каникулларны күңелле итеп үткәрәчәген сөйли.

— Безнең мәктәп каникулларны үткәрүгә яхшы хәзерләнде. Яңа елны каршылау кичәсе үткәрелә һәм елка оештырыла.

Каникул көннәрендә күп кенә балаларның өйләрендә дә елкалар ясала. Балалар бер-берсенә кунакка барачаклар, елка янында рәхәтләнеп күңел ачачаклар.

Аннары безнең мәктәп Казан—Шеланга—Казан маршруты буенча хәрбиләштерелгән чаңгы походы оештыра. Мин бу походка катнашам. 70 километр арада үткәрелә торган чаңгы походы 3—4 көн дәвам итәчәк. Шул чакта без Шелангыдагы ял йортында кунакта булачакбыз.

КАНИКУЛ КӨННӘРЕНДӘ

Залның бер почмагында нәни лампа янып китә һәм Карбикә күренә. Ул Кыш бабайдан балаларга сәлам китергән.

— Бераздан бирегә үзе дә килеп җитә,—ди.

Балалар арасында күңелле хәрәкәт. Карбикә югалу белән икенче бер урында ут янып китә. Балалар аюны күрәләр. Ул Кыш бабайдан телеграмма килгәнлекне белдерә. „Инде юлда, тиздән килеп җитәм“—дигән Кыш бабай.

Нәни куян бөтен залны яңгыратып кычкыра:

— Юл бирегез, җыелыгыз! Кыш бабай килә, Кыш бабай!

Җил ыжгыра... Кыш бабай килеп чыга. Балалар белән исәнләшкәннән соң, ул елка янында үзенең программасын башлап җибәрә.

Казанның укучылар һәм пионерлар йорты каникуллар вактында көн саен зур елка бәйрәме үткәрәчәк. Бу бәйрәмгә хәзерлекне балалар үзләре алып бардылар, аны үткәрүдә дә барлык рольләрне алар үзләре башкаралар. Елка янындагы зур бәйрәмнән тыш балалар бу йортта тагын бик күп нәрсәләр күрә алалар.

Бүлмәләрнең берсе әкиятләр бүлмәсе итеп бизәлгән. Анда төрле әкиятләр сөйләнелә. Ә бу бүлмә белән рәттән—баснялар бүлмәсе. Биредә балалар үзләре төрле баснялар белән чыгалар. Ә каршыдагы бүлмәдә музыкаль викторина бара. Музыка әсәрләрен, аларның авторларын яхшы белүчеләр бүләкләр алалар.

Табышмаклар, шарадалар, ребуслар бүлмәсе бар. Иң тиз һәм яхшы бирелгән җавапларга призлар бирелә.

Коридорның бер башында кечкенә генә тау ясалып куелган. Анда кечкенә балалар нәни паласларга утырып шуалар.

Пионерлар йортында, каникуллар вактында, тәртипле рәвештә кино, үзешчәнлек коллективларының чыгышлары, Дәүләт филармониясе артистларының концертлары, курчак театры постановкалары һәм башкалар булачак. 11 көн эчендә барлыгы 25 меңгә якын балага хезмәт күрсәтергә уйланыла.

***

Театрлар һәм кинолар каникуллар вактында махсус программа белән эшләячәкләр. Татар Дәүләт Академия театрында балалар өчен А. Әхмәтнең „Ни чәчсәң шуны урырсың“ дигән пьесасы куела. Зур Драма театры 5 һәм 6 нчы январьда балаларга „Дядя Ваня“ны күрсәтә. Татар Опера театрында „Евгений Онегин“ куела. Яшь тамашачылар һәм курчак театрлары, Дәүләт циркы каникуллар вактында күрсәтү өчен махсус программа хәзерләделәр.

Кино-театрларда балалар өчен сеанслар биреләчәк.

Клублар каникулларны зур хәзерлек белән каршыладылар. Аларда елкалар куелды һәм төрле темаларга махсус бүлмәләр бизәлде. Кызыл Армия геройлары һәм Татарстанның атаклы кешеләре белән балаларның очрашулары үткәрелә.

Каникуллар вактында балалар „Штурмга!“ дигән хәрби уенда катнашалар. Шәһәр физкультура комитеты укучыларның коньки ярышларын үткәрергә уйлый. Шәһәрнең барлык катоклары, чаңгы станцияләре балаларга хезмәт күрсәтү өчен махсус сәгатьләр билгелиләр. „Динамо“ җәмгыяте балалар өчен каток ясый.

Каникул көннәре шундый зур күтәренкелек һәм шатлык белән башлана. Бу көннәрдә балалар киләчәктә укуны яхшы дәвам иттерү өчен иң яхшы зарядка алачаклар.

Г. Хәлим.

55 нче номерлы мәктәпнең (Казан) I нче классында укучы Инна Поляков елка бәйрәменә хәзерләнә.

И. Галиев фотосы.

КҮҢЕЛЛЕ КӨН

Бүген әни бик кызык,
Кайтып керде дә:
— Кызым!

Бир әле,—ди,—кәрзинне!
Киендер,—ди,—Кәримне!

Үзе никтер елмая.
Үзе сорый:
— Кем, кая!

Абыегызны әйтәм...
Ник кайтмый инде Әхтәм?

Үзе гел безгә табан
Карап елмая һаман.

Кызык соң безнең әни—
Уйлап кайткан әллә ни...

Әнкәйдән сорый Кәрим:
— Нәрсәгә,—дип,—бу кәрзин?

Аңар өстәп мин сорыйм:
— Кайда барабыз соң?...—дим.

Әни әйтә гел бер сүз:
— Барып җиткәч күрерсез.

Чыгып барган чагында,
Абый кайтты чаңгыда.

Аптырап калды абый:
— Мунчагамы әллә?—ди.

Әни әйтә гел бер сүз:
— Барып җиткәч белерсез.

Чыгып киттек без шулай:
Әни, мин, ике малай.

Ял көне бит. Урамнар
Шау-гөр килеп торалар.

Таныш-белешләр очрый.
Барсы да бездән сорый:

— Дүртәүләшеп кай якка?
— Кемгә,—диләр,—кунакка?..

Аларга да шул бер сүз:
— Озакламый белерсез.

Һаман барабыз шулай:
Әни, мин, ике малай...

И күңелле. И кызык...
Берсе-берсеннән узып,
Тегендә-монда табан,
Автомобильләр чаба.

— Шофер абый, бер тапкыр
Шул турыда туктап тор!—
Урам аша үткәнче,
Каршы чатка җиткәнче.

Шофер абый аптырый,
Туктый да бездән сорый:
— Дүртәүләшеп кай якка?
Барасызмы еракка?..

Әни әйтә аңарга:
— Юлның яртысы алда.

Шуннан соң шофер абый,
Артык берни сорамый,
Дүртебезне утыртып,
Алып китте очыртып.

Йортлар калды як-якта.
Утлар балкый еракта—

Күге дә бар, агы да,
Зәңгәре дә, алы да...

Барып җиткәч шунда без,
Туктады машинабыз.

Шофер абыйга рәхмәт!
Сизми дә калдык рәтләп—
Ничә урам үткәнне,
Ничек килеп җиткәнне.

Каршыбызда зур кибет
Шаулап тора гөр килеп.

Түшәмендә фонарьлар
Шундый якты яналар.

Әни әйтә:
— Шушы!—ди,
— Килгән юлның очы,—ди.

— Яхшы укыган өчен,
Отличник булган өчен,
Каникул көнегезгә
Елка ясыйм мин сезгә!

Елка өчен ни кирәк,
Уенчык яки бизәк,
Сайлап алыгыз барын,
Иң шәбен, матурларын!

Ишек ачып керүгә,
Кибет эчен күрүгә—

Ис тә, акыл да китте,
Бизәгәннәр шул тикле

Кибетнең иң түрендә,
Зур бер чыршы төбендә—

Басып тора Кыш Бабай—
Безгә бик таныш бабай.

Бала-чага барсы да,
Туктап аның каршына,

Ымлашып кул болгыйлар:
— Бик сагындык шул...—диләр.

Ул чыршысы, чыршысы!
Ялтырый һәр ширпысы.

Һәр ботагында аның
Нәрсәсе юк дөньяның:

Һималай аюлары,
Джунгли маймуллары,

Тутый кошы дисеңме,
Болан, пышый дисеңме,

Бүтән җәнлек дисеңме...
Китәрерлек исеңне.

Әй син, хәйләкәр төлке,
Колакларыңны селкеп,

Нишләп торасың анда
Күзең текәп куянга?..

Әй, ак куян, ак куян!
Син монда килдең каян?

Урманнанмы, кырданмы?
Күрмәдеңме торнаны?

Әнә икән ул үзе!
Челәйтеп тора күзен.

Аның артына поскан
Ала канат саескан.

Ниләр генә юк бире:
Төя, арыслан, бүре,

Озын муенлы аккош,
Гөберле бака, кыскыч,

Күбәләкләр, тавыклар,
Алтын тәнле балыклар...

Күр әле, күр!..—оядан
Карап тора баядан,

Күтәреп бер сыйрагын,
Салпыратып колагын,

Кызыл телле „Алабай“,
Кәкре коерыклы маэмай.

— Әни,—дим... Әни... Әни!..
Күрәмсең нинди нәни

Аэроплан ботакта.
Канатлары як-якта.

Шуны миңа алып бир!
Парашютын тагып бир!

Әхтәм миннән дә өлкән—
Тугызы тулып үткән.

Онытты ул да бүген
Үзенең өлкәнлеген.

Ул да әйтә әнигә:
— Алып кайтыйк,—ди өйгә.

Танк белән җиз боргы,
Балалайка, сыбызгы...

Җиңен тартып әнинең
Такылдап китте энем:

— Тегесен ал!.. Бусын ал...
Алтын буяулысын ал!

Барын да ал, барсын да!
Этен дә, оясын да,

Ак аю баласын да...
Барсын да ал, барсын да...

Төяләрне төядек.
Төргәкләргә төйнәдек—

Фонарьларны, чукларны,
Төрле уенчыкларны.

Туптулы булды кәрзин.
— Мин күтәрәм!—ди Кәрим.

Әни әйтә:—Әйдәгез!
Кайтыр тиздән әткәгез—
Чыршы сайлап урманнан,
Иң матур бер аланнан.

Кайтып киттек без шулай:
Әни, мин, ике малай...

Кави Нәҗми.

Чит илләрдә

Англия - Германия сугышы

ГЕРМАНИЯ ХӘБӘРЛӘРЕ

БЕРЛИН, 29 декабрь (ТАСС). Верховный командованиенен хәбәр итуенә караганда, Атлантиканың төньягында Германиянең дингез көчләре дошманның көчле сакчылар белән бара торган каравандына һөҗүм итеп, 6 мең тонна авырлыктагы бер пароходны батырганнар һәм икенчесен бик нык зарарлаганнар. Дошман сугышы туктатырга мәҗбүр булган.

Кичә Германиянең бер самолеты Саутгемптонның порт корылмаларын бомбага тоткан. 29 нчы декабрьгә каршы төндә Германия авиациясе Ла-Манш ярындагы бер порт шәһәрен бомбага тоткан.

Үткән төнне Германия территориясенә бомбалар ташланмаган. Оккупацияләнгән территориягә ташланган бомбалар зур зиан китермәгәннәр. Англиянең бер самолеты бәреп төшерелгән.

Германия информация бюросының хәбәр итуенә караганда, үткән төнне Лондонга гаять зур зарар китерелгән. Гайдпарктан төньякта һәм көнбатышта 6—8 километр буена зур янгын күренгән.

АНГЛИЯ ХӘБӘРЛӘРЕ

ЛОНДОН, 29 декабрь. (ТАСС). Рәсми рәвештә хәбәр ителүенчә, кичә кич белән Германия бомбардировщиклары Көньяк-Көнбатыш Англиядә бер шәһәрне бик каты бомбага тотканнар. Янгыннар тиз сүндерелгән. Корбаннар саны бик аз.

Рейтер агентлыгы Англия авиациясенең Германия оккупацияләгән Франция портларын 28 нче декабрьдә кич белән бомбага тотканлыгын хәбәр итә. Самолетлар вакыт-вакыт минутына йөз бомба ташлаганнар.

ЛОНДОН, 29 декабрь. (ТАСС). Рейтер агентлыгы 29 нчы декабрьгә каршы төндә Көньяк-Көнбатыш Англиянең бер шәһәренә Германия авиациясе ясаган һөҗүм турында тулы хәбәрләр бирә. Һөҗүм, озак дәвам итмәгән булса да, сугыш башланганнан бирле бу шәһәргә ясалган 240 һөҗүмнең барсыннан да көчлерәк булган. Нәтиҗәдә шактый күп материал зиан китерелгән. Бик күп магазиннар һәм йортлар җимерелгән. Күп кешеләр йорт-җирсез калганнар. Шәһәрнең төрле районнарында 20 дән артык янгын чыккан.

ЛОНДОН, 29 декабрь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итуенә караганда, 29 нчы декабрьдә кич белән Лондонда һава тревогасы игълан ителгән. Һөҗүмнең сугыш башланганнан бирле иң көчле характерда булачагына алдан ук ышанырга мөмкин булган. Шәһәрнең күп районнарына Германия самолетлары башта яндыргыч бомбалар, соңыннан фугаслы бомбалар ташлаганнар.



Рәсемдә: Италиянең көнбатыш Сахрадагы (Ливиядәге) күзәтү вышкасы. ТАСС фотосы.

Греция-Италия сугышы

ЛОНДОН, 29 декабрь. Рәсми рәвештә хәбәр ителүенчә Тепелене районында сугыш хәрәкәтләре хәл иткеч чорга керәләр. Италия гаскәрләре гадәттән тыш көчле позицияләрдә торалар, лакин шулай булса да грекларның алга баруларын туктата алмаганнар.

НЬЮ-ЙОРК, 29 декабрь. Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, греклар Тепеленене чолгап алалар. Хәзер инде алар шәһәр тирәсендәге биеклекләрне алганнар. Итальяннардан күп кешеләр плен алынганнар һәм күп сугыш материаллары кулга төшерелгән.

АФИНА, 29 декабрь. Газеталарның язуына караганда, төньяк участкының күп кенә секторларында греклар фронтны өзгәннәр. Итальяннардан 200 солдат һәм офицерлар плен алынган. Химара секторында греклар итальяннарның линиясен өзеп үткәннәр. Клисура районындагы сугышларда 400 ләп итальян плен алынган.

БЕЛГРАД, 29 декабрь. „Политика" газетасының язуына караганда, төньяк фронтта грек гаскәрләре соңгы сугышларда бик авыр корбаннардан соң тирән кереп һәм тау юллары аркылы Лин шәһәренә барып чыкканнар. Анда бик каты сугышлар башланган. Лин артында шактый җирне барып урнашканнар. Греклар шәһәрдән бер километрда торалар.

АФИНА, 29 декабрь. Кичә Греция верховный командованиесе түбәндәге сводканы игълан итте. „Безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә җирле характердагы операцияләр үткәрделәр. Шактый гына итальяннар плен алынды". (ТАСС).

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Фронтның аерым участкыларында япон гаскәрләре җирле характерда берничә операция үткәреп, кытайларның позицияләренә һөҗүм иткәннәр. 26 нчы декабрьдә Хубэй провинциясенең үзәк өлешендә японнар Ичаннан көнчыгыштарак Лунчжуаньпу якынында кытайларның позицияләренә һөҗүм ясаганнар, ләкин, кытайлар бик нык каршылык күрсәткәнлектән, чигенергә мәҗбүр булганнар. Цзянси провинциясенең төньяк өлешендә японнар кытайларның Наньчаннан көньяк-көнчыгыштагы позицияләренә һөҗүм иткәннәр. Бер сәгать сугышканнан соң һөҗүм кире кайтарылган.

24 нче декабрьдә Цзикоу районында японнарның Янцзы елгасыннан бара торган хәрби катеры минага бәрелеп баткан.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә сугышлар Цзиньчэн районында баралар. Бу секторда японнар отряды, артиллерия ярдәме белән, кытайларның позицияләренә һөҗүм иткән. Провинциянең көньяк-көнбатыш өлешендә кытай гаскәрләре Цзясяннән көньяктарак японнарның позицияләренә һөҗүм ясаганнар һәм аларга шактый зур зиан китергәннәр.

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Кантон якынына японнарның биш дивизиягә якын зур көчләре туплана. Япон командованиесе Гуандун провинциясенең төньяк өлешендә зур операцияләр хәзерли дип уйлыйлар.

***

Японнардан алынган хәбәрләргә караганда, 27 нче декабрьдә Япониянең дингез авиациясе Хубэй провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә Гуансиньны бомбага тоткан. Шәһәрдә җимерелүләр бар.

29 декабрь. (ТАСС).

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

— Франциянең Пюи-де-Дом департаментында соңгы өч ай эчендә 60 кеше яшерен эш алып баруда гаепләнеп концентрация лагерьларына җибәрелгәннәр.

— Якын араларда Англиядә тизләтелгән методлар белән стандарт караблар төзү башлана. Карабларның аерым кисәкләре заводларда эшләнәчәк һәм соңыннан, җыю өчен, караблар верфьләренә җибәреләчәк.

— Музыкаль талантлары булган балалар өчен Чунцин янында мәктәп бар. Балалар барсы да дәүләт һәм җәмәгатьчелек тәрбиясендә торалар. 26 нчы декабрьдә алар концерт бирделәр. Концерт зур уңыш белән үтте. 15 яшьлек бер малай дирижерлык итте.

— Эквадорда барлык мәктәпләрдә сугыш эшенә өйрәтү кертелгән. Шулай ук 18 дән 50 гә кадәр булган барлык гражданнар сугыш эшенә өйрәтеләчәкләр. Алар милли гвардия составына кертеләчәкләр.

— Кытайның Кызыл Хач җәмгыятендә 140 мең член бар. Фронтларда җәмгыятьнең 90 врачлык пунктлары эшли. Медицина эшчеләре 2.700 кешедән тора. Америкадан ай саен 50 мең долларлык ярдәм алына.

Шагыйрь Сәйфи Кудаш Казанда

Бик күп шигырьләре һәм поэмалары белән башкорт һәм татар хезмәт ияләре арасында киң популярлык алган совет язучысы Сәйфи Кудаш Казанга килде.

Сәйфи Кудашның шигырьләре матбугатта 1915 нче елдан башлап күренә башлыйлар. Ләкин бу чорларда әле анарда, язучы буларак, ныклы бер эзгә басу булмый.

Аның чын иҗад активлыгы илдә Совет власте урнашкач башлана. Аның төп темасы — совет авылы, колхоз. Бу темага язылган «Дим буенда», «Элемтә», «Утауда», «Киләләр», «Хат», «Мәхәббәт», «Тау кызы» һәм бик күп башка шигырь һәм поэмалары аның күренекле әсәрләреннән саналалар. Зур полотнода шигырь белән язылган «Кушкаен» романы С. Кудаш иҗадының характерлы үрнәге булып тора.

Ул, шулай ук, хикәяләр дә һәм балалар өчен шигырьләр дә яза.

С. Кудашның хәзерге көндә аерым исемнәрдә чыккан 26 китабы бар. Шагыйрь хәзер «Кушкаен» романының икенче кисәген тәгәлли. М. Гафури турындагы пьесасы язылып бетү алдында тора.

Бүгенге көндә Татгосиздатта С. Кудашның зур күләмдә шигырьләр җыентыгы чыгарылырга хәзерләнә.

Татрадиокомитет шагыйрьнең радио буенча чыгышын оештырды. Язучылар Союзында С. Кудаш белән татар совет язучыларының очрашулары үткәрелде. С. Кудаш Казанда берничә көннәр булачак.

СӘЙФИ КУДАШ

БӘЙРӘМ ҖЫРЫ

Тагы да ишәйде семьябез,
Тагы да ямләнде табын.
Бәхет кояшы астына
Дүрт туган керде тагын.
Шуңа бәйрәм елдагыдан—
Ямлерәк тоелып тора,
Шуңа бәйрәм ашлары да
Тәмлерәк тоелып тора.
Семьянең яшь членнарын—
Әйдәгез котлыйк әле,
Кулга тоткач бокалларны,
Талдырып тормыйк әле!
Атабызның хөрмәтенә
Аякка басыйк әйдә,
Бәйрәмне тагын шатлыклы,
Шаулырак ясыйк әйдә!
Киләсе бәйрәмгә кадәр
Тагын ишәйсен табын,
Бәхет кояшы астына
Туганнар керсен тагын!

1940 ел, декабрь.

УКУЧЫЛАРНЫҢ ШАХМАТ-ШАШКА ЯРЫШЛАРЫ

Казанның Пионерлар һәм Укучылар йорты кышкы каникуллар вакытында, физкультура-спорт комитеты белән берлектә, укучылар арасында шахмат-шашка ярышлары үткәрә. Бу ярышларда Казан мәктәпләренең сайлама командалары катнашачак. Җиңеп чыккан команда бүләкләнә.

Ярышлар Пионерлар йортында 3 нче январьда башланачак.

Казан пехота училищесенең курсантлары чаңгы тренировкасында.
В. Лаврентьев фотосы.

Сайлау округына чаңгы походы

СССР Верховный Советына сайлаулар буенча Яңа Чишмә сайлау округына Казан физкультурникларыннан 6 кешелек махсус бригада чыгарыла. Бригадага Татарстанның күренекле спортчысы—Казан Дәүләт Педагогия институтының доценты М. Абдрахманов җитәкчелек итәчәк.

Бригада Каргалы, Яңа Чишмә, Яңа Ибрай, Аскубай һәм Шәле авылларында булачак. Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе турында, Кызыл Армиягә призыв, илнең оборонасында чаңгы спортының әһәмияте, халыкара хәлләр һәм башкалар турында колхозчылар, эшчеләр һәм хезмәткәрләр арасында беседалар, докладлар һәм лекцияләр үткәреләчәк.

Кызыл Армиянең 23 нче еллыгына багышлап комсомол тарафыннан үткәрелә торган чаңгы кроссында катнашуга хәзерлек буенча бригада махсус эш алып барачак.

Югарыда күрсәтелгән авылларның берсендә колхозчы яшьләрнең чаңгы ярышларын үткәрергә уйланыла.

Х.

Каникуллар оешкан рәвештә үтәчәк

АЛАБУГА. (Үз хәбәрчебездән телефон буенча). Район мәгариф бүлеге мәктәп балаларының кышкы каникулларын оешкан рәвештә үткәрү буенча барлык мәктәпләргә план җиткерде. Хәзер мәктәпләрдә каникулга хәзерлек эшләре алып барыла. 1 нче һәм икенче январьда барлык мәктәпләрдә дә яңа ел елкалары үткәреләчәк. Барлык урыннарда укучылар көче белән елкаларны бизәү эше бара.

Алабуга шәһәрендәге Пионерлар Клубында бөтен шәһәр өчен зур елка хәзерләнә. Каникул вакытында пионерлар клубында укучы балалар белән СССР Верховный Советы депутаты очрашачак һәм хәрби часть вәкиле белән кышкы спортның оборона эшендәге әһәмияте турында беседа үткәреләчәк.

Каникул вактында мәктәпләрдә кышкы спорт эше киң рәвештә оештырылачак. Шәһәрдә мәктәп балалары өчен зур каток ачыла. Өлкән классларда укучылардан Танәйкә урманына чаңгы походы оештырыла. Морт авылындагы урта мәктәп балалары өчен каток, коньки һәм 40 пар чаңгы хәзерләнә. Биредә каникул вактында оешкан рәвештә конькида өйрәнү булачак.

Җиңел автомобильләре булган барлык предприятиеләргә һәм учреждениеләргә

Татарстан АССР Совнаркомы җиңел автомашиналары булган барлык предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең җитәкчеләренә 1941 нче елның январь аена бензин алу өчен лимит кенәгәләренең ТАССР Совнаркомы янындагы Автомобиль Транспорты идарәсендә 31 нче декабрьдән 4 нче январьга кадәр бирелүен белдерә (Казан, Островский урамы, 2, телефон 2—11).

Лимит кенәгәләре алу өчен ТАССР Совнаркомы янындагы Автомобиль Транспорты идарәсенә барлык җиңел машиналарның исемлеген бирергә, аларның маркаларын, лимит группаларын, дәүләт номерларын һәм серияләрен күрсәтергә кирәк. Исемлеккә учреждениенең җитәкчесе һәм автобаза начальнигы кул куярга тиеш.

Татарстан АССР Совнаркомы.

Җаваплы редактор Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответственный редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

ЧЕГӘН аттракционының саубуллашу гастрольләре
1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9 нчы январьда
Соңгы 9 көн. 1, 2, 3, 4, 5 нче январьда көндез 12 сәгатьтә башлана.

ЯҢА ЧЕГӘН РОМАНСЛАРЫ — ЯҢА ҖЫРЛАР ҺӘМ БИЮЛӘР.

АМИ аттракционының саубуллашу гастрольләре.
Әйләнеп тора торган дирижабль тирәсендә планерда очу һәм күп кенә яңа номерлар. Уен кич 8 сәгать 15 минутта башлана. Касса иртән 9 дан кич 9 сәгатькә кадәр ачык.

ИГЪТИБАР! Циркның ял көне 6 нчы январьдан—дүшәмбе көннән 10 нчы январьга—җомга көнгә күчерелә.
11 нче январьдан башлап РСФСР ның атказанган артисты орденлы В. Эйкенның художество җитәкчелегендә яшьләрнең өченче цирк труппасы— „Күңелле теплоход" гастрольләре.

Зур Драма Театры
Бүген
АНДЖЕЛО

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
3 нче январьда
ЧИО-ЧИО-САН

БҮГЕН КИНОЛАРДА:

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да. — Кино-новелла ЮЛЛАРДА
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да — Яңа художестволы фильм КАЙТУ. 16 яшькә кадәрге балалар кертелми.
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 4, 6, 8, 10 да. — СТЕПАН РАЗИН
„ПИОНЕР" 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5, 6-30, 8, 10. — Көндез Геройның энесе. Кич Бишенче океан
„Колхозник" 4, 6, 8 һәм 10 да — КАЙТУ. 16 яшькә кадәрге балалар кертелми.
„ЧАТКЫ" 4, 6, 8 һәм 10 да — Яңа, тавышлы художест. фильм ЮЛЛАРДА
„РОТ-ФРОНТ" [illegible] — [illegible]
КУЛЬТУРА САРАЕ [illegible] — ВАТАН КЫЗЫ

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген кич
Г. Камал әсәре
БӘХЕТСЕЗ ЕГЕТ
Бүген балалар өчен
„Ни чәчсәң шуны урырсың",
иртәнге спектакль көндез 3 сәгатьтә башлана. „2" билгесе куелган билетлар ярый. 1941 нче елның 1 нче январында көндезге спектакль көндез 12 сәгатьтә башлана. „1" билгесе куелган билетлар ярый. Касса иртән 11 сәгатьтән ачык.
Билетлар сатыла.

Казан трамвае капиталь төзелеш бүлегенең урланган түгәрәк печатен 1940 нчы елның 27 нче декабреннән гамәлдән чыккан дип санарга.

1941 нче елның 20 нче январенда, 18 сәгатьтә, Казан Ветеринария институтының актовый залында. Төрекмәнстан Авыл Хуҗалыгы институтының эпизоотология кафедрасы мөдире Г. Ф. Панин тарафыннан „Мөгезле эре терлекләрдәге ниоэндометритларның һәм вакытсыз абортларның сәбәпләре һәм аларга каршы көрәш чаралары" дигән темада
ДОКТОРЛЫК ДИССЕРТАЦИЯСЕ ЯКЛАУ БУЛА
Рәсми оппонентлар: профессор М. Н. Верещагин, профессор Н. П. Попов, профессор А. П. Студенцов.
Диссертация материаллары белән институт китапханәсендә танышырга мөмкин.
2581-1-1

ТАТНАРКОМЗЕМ ЯНЫНДАГЫ „ВОДСТРОЙ"НЫҢ
республика конторасы Татарстан территориясендә сугару, буалар, плотиналар ясау, водопроводлар үткәрү, торф чыгару, буровой коелар казу, җил двигательләрен монтажлау һәм башкалар буенча проект-эзләнү һәм төзү эшләренә 1941 нче елга
ДОГОВОРЛАР ТӨЗҮ ЭШЕНӘ КЕРЕШТЕ
Заказларны җибәрү өчен адрес: Казан шәһәре, Кремль, Наркомзем, бүлмә № 3, телефон № 38—26.
2566-2-2

„СПАРТАК" КОМБИНАТЫНЫҢ
ФЗУ МӘКТӘБЕ
1941 нче елның 1 нче январеннан 1 нче февраленә кадәр
укучылар ала
Мәктәп „Спартак" күн аяк киемнәре комбинаты өчен квалификацияле кадрлар хәзерли. Кабул итү шартлары түбәндәгечә: мәктәпкә 15 тән 18 яшькә кадәрге кешеләр алына, керү өчен урта мәктәпнең 7 классыннан түбән булмаган күләмдә белем кирәк. Кабул итү сынаулары (ана теленнән һәм математикадан) 1 нче февральдән 5 нче февральгә кадәр үткәрелә.
Мәктәпкә алынучылар өлгерешләренә карап аена 70 сумнан 140 сумга кадәр хезмәт хакы белән тәэмин ителәләр. Районнардан килүчеләргә гомуми торакта урын бирелә. Мәктәпкә керергә теләүчеләр гариза белән берлектә яше, белеме, сәламәтлеге һәм даими тору урны турында таныклык һәм белешмә бирергә тиешләр.
Адрес: Казан, Татарстан урамы, йорт № 8.

ЮГАРЫ ВОЛГА ЕЛГА ПАРОХОДЧЫЛЫГЫНЫҢ
КАЗАН ПРИСТАНЕ
1941 нче елгы навигациядә барлык юнәлешләргә зур тизлек белән һәм Казан пристане районында аз тизлек белән елгаларда йөк йөртү өчен
1941 нче елның 5 нче январеннан
ДОГОВОРЛАР ТӨЗҮ ЭШЕНӘ КЕРЕШӘ
[illegible]

ТАТАРСТАН АССР НАРКОМФИНЫ
Барлык предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар игътибарына белдерә, алар, халыктан доход налогы алу турындагы законның 12 нче статьясе нигезендә, 1940 нчы елның 4 нче квартал өчен эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән доход налогы һәм культура җыемы тотып калу турында (1941 нче елның 1 нче январена булган торышында) отчет бирергә тиешләр.
Отчетларны предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар урнашкан урыннарда район яки шәһәр финанс бүлекләренә 1941 нче елның 10 нчы январеннан да соңга калмыйча бирергә.
Отчет бланклары район (шәһәр) финанс бүлекләрендә бирелә.
Отчет бирмәгән өчен яки вакытында бирмәгән өчен, отчет бирергә җаваплы булган кешеләр 100 сумга кадәр штрафка тартылалар.
ТАССР Наркомфины.
2460-1-1

ТАТНАРКОМХОЗ СИСТЕМАСЫНДАГЫ
ДӘҮЛӘТ ПРОЕКТ КОНТОРАСЫ
„ТАТКОМПРОЕКТ"
гражданский һәм промышленность төзелешләренең комплекслы объектлары өчен проектлар һәм сметалар үтәүгә, шулай ук биналарны реконструкцияләү һәм өскорма буенча, янгынга каршы тышкы һәм эчке хуҗалык водопроводларын һәм канализацияләрне реконструкцияләү буенча, җылыту һәм вентиляция системасы буенча аерым төрләрдәге проект-смета эшләрен үтәүгә
ЗАКАЗЛАР АЛА
Заказлар кыска срокларда үтәләләр. Тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итү өчен адрес: Казан, Куйбышев мәйданы, йорт № 9, заказлар өстәле, телефоннар: 57 һәм 4—3.
2574-1-1

ГАСТРОНОМНЫҢ КАЗАН РЕСПУБЛИКАНСКАЯ КОНТОРАСЫ
1941 нче елның 1 нче январеннан Главгастроном системасындагы магазиннарның расчет һәм махсус ссудалар счетлары ябылганлыкны белдерә:
1 нче номерлы Гастроном магазины, расчет счеты № 60084, махсус ссудалар счеты № 6113084.
2 нче номерлы бакалея магазины, расчет счеты № 6086, махсус ссудалар счеты № 6113086.
3 нче номерлы бакалея магазины, расчет счеты № 60087, махсус ссудалар счеты 6113087.
4 нче номерлы бакалея магазины, расчет счеты № 6085, махсус ссудалар счеты № 613035.
5 нче номерлы бакалея магазины, расчет счеты № 6090, махсус ссудалар счеты № 61300.
[illegible]

Якын көннәрдә Татарстан АССР кино-театрлары экраннарына „Гүзәл большевикларның тормышы" дигән циклдан
„ЯКОВ СВЕРДЛОВ"
дигән зур тарихи - биографик яңа фильм чыгарыла.
Атказанган сәнгать эшлеклесе орденлы Сергей Юткевич тарафыннан орденлы язучылар Левин һәм Павленколар сценарие буенча эшләнгән бу гүзәл фильмдә Яков Михайлович Свердлов биографиясенең, үзенең бөтен гүзәл тормышын Ленин—Сталин эшенә биргән гүзәл большевик биографиясенең төп этаплары художество ягыннан гаять көчле итеп чагылдырылган.
Фильмдә большевиклар партиясенең бу талантлы оештыручысы, хезмәт ияләренең киң массасы тарафыннан тирән мәхәббәт казанган Я. М. Свердлов бөтен күләме белән бирелгән.
Экранда яшь большевикның беренче адымнарыннан алып Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты председателе постында үлүенә кадәр Яков Михайлович Свердловның тормышы күз алдыннан үтә.
Свердлов подпольный эшне Нижний-Новгородта башлый; 1905—1906 нчы елларда Уралда большевистик оешмага җитәкчелек итә; төрмә, Туруханск сөргене һәм иптәш Сталин белән очрашу, учредительный собраниене тар-мар итү; Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты председателе постында гаять тыгыз күп яклы кайнап торган эш— Свердлов биографиясендәге шушы төп этаплар фильмдә ачык итеп күрсәтелгәннәр.
Ленин һәм Сталин образларын РСФСР ның атказанган артисты орденлы Штраух һәм артист Кобаладзе бик яхшы итеп бирәләр. РСФСР ның атказанган артисты орденлы Любашевский Свердлов ролен гаять зур осталык белән башкара.
Фильмдә шулай ук орденлы артистлар Крючков, Охлопков һәм башкалар катнашалар.
„Яков Свердлов" фильме талантлы, җанлы һәм тәэсирләндерерлек әсәр.
Шушы елның 4 нче декабрендә „Правда" газетасы болай дип язды:
„Илебезнең һәм бөтен дөньяның миллионнарча кешеләре бу фильмне гаять кызыксынып карарлар һәм героик эпоханы башларыннан кичерерләр. Бу эпоха шартларында бөек большевиклар партиясе үсте һәм чыныкты, дөньяга тимердәй рыцарьларны, пролетар революция геройларын бирде. Бу геройлар арасында Яков Михайлович Свердлов мактаулы урын тота".
2578-1-1

Сталин районының 6 нчы участкы суд башкаручысы Яшләр урамындагы 26 нчы номерлы йортка (45 квадрат метр) 3 нче январьда
ТОРГИ
игълан итә
Торги шул ук йортта була.
Суд башкаручысы ИОНОВ.
2575-1-1

Казан Медицина институтының тире авырулары клиникасы янындагы
КОСМЕТИКА ҺӘМ ГИГИЕНА КАБИНЕТЫ
(Толстой урамы, йорт № 4, телефон № 3—7.)
бетчәне, сыткыны, сипкелне һәм тиредәге кимчелекләрне (сөялне, миңне)
дәвалый,
биткә массаж ясый, тирене һәм чәчне дәвалый.
Кабул итү түләүле. Гомуми ял көненнән башка һәр көнне кич 4 тән 8 сәгатькә кадәр кабул ителә.
2557-10-3

„Уку Ударнигы" газетасы һәм „Совет мәктәбе" журналы [illegible]
КӘШИФӘ ӘХМӘТҖАНОВА
[illegible]

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: пропаганда бүлеге һәм экономик бүлек 18—22, секретариат 5—86, партия бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, төнге редакция 3—75, типография 33—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.
ПФ 3894 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ. 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 5599.